**Галиев Вахит Вәлиевич**

# ҖЫРЛАРЫМДА ГОМЕРЕМ ДӘВАМЫ

## Шигырьләр

ШИГЫРЬЛӘР
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Г18

**Галиев В.В.**

Җырларымда гомерем дәвамы: Шигырьләр / Вахит Галиев; Кереш сүз авт. Ә.Гадел.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 208 б.

ISBN 5-298-04007-1

Татарстанның чал тарихлы, гүзәл табигатьле Мамадыш шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь Вахит Галиевнең әлеге китабы — унынчысы. Анда шагыйрьнең соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләре тупланган.

ISBN 5-298-04007-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Галиев В.В., 2006

### ТАБИГАТЬ ЧИШМӘСЕ УЛ...

*Киләсе елның гыйнвар аенда 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк Вахит ага Галиевнең тормыш юлы катлаулы да, сокландыргыч та. Бала чагыннан ук тормыш арбасына җигелергә туры килә аңа. Әтисе шахталарда эшләгәндә, сугыш белән дә күзгә күз очраша, ачлык михнәтләрен дә татый ул. Буыннары да ныгып бетмәгән килеш колхоз эшендә дә катнаша. Унҗиде яшеннән солдат шинеле кия. Полк мәктәбен, хәрби училище тәмамлый. Армиядә кыскартулар башлангач, язмыш аны Урта Азия якларына китереп чыгара. Анда бераз гомер иткәч, туган төбәгенә — Иске Комазанга әйләнеп кайта Вахит ага.*

*Монда аңа урман хуҗалыгында мастер да, әзерләүче дә, авыл советы рәисе дә, җәмәгать башлангычында клуб мөдире дә булып эшләргә туры килә. Уразбахты авылындагы «8 нче март» колхозына җитәкче итеп тә билгеләнә. Авылның исеме «бәхет бакты» мәгънәсен аңлатса да, беренче айларда бәхет аның тарафына борылырга теләми. Какча гәүдәле Вахитны Уразбахтының эре сөякле һәм тәкәббер ирләре танымыйлар. Авылның иң «разбуй» кешесе берзаман аны — колхоз рәисен — «акылга утыртмакчы» була, тик десантчы-офицер аны бик тиз бөтереп ала. Авыл халкының ихтирамын эше, үҗәтлеге, гаделлеге белән яулый ул. Бергәләшеп колхозны күтәрәләр, авылны яңарталар. Уразбахтыда дистәләгән яңа йортлар, ике катлы мәктәп, хуҗалык идарәсе, ашханә, кунакханә, уннан артык терлекчелек бинасы, Омар елгасы аша күпер җиткерелә. Казан — Чаллы трассасына кадәр юл күтәртелә. Вахит ага үзе «Хезмәт отличнигы» медаленә, комсомол яшьләр фермасы Муса Җәлил исемендәге премиягә лаек була. Ул Татарстан колхозлары арасында әлеге мәртәбәле премияне алучы бердәнбер коллектив санала.*

*Аннан Вахит Галиев район нефтебазасында директор булып эшли. Биредә дә коллектив аның җитәкчелегендә матур күрсәткечләргә ирешә. Илдә икътисади үзгәрешләр, финанс кыенлыклары башланса да, район хуҗалыкларын өзлексез ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итүне оештыра. Янәшәдәге район хуҗалыкларына да ярдәме күп тия. Монда 70 яшенә кадәр эшли ул.*

*Лаеклы ялга чыккач та, өендә кул кушырып утырмый. Республика татар иҗтимагый үзәгендә актив эш алып бара. Татарстан Аксакаллар шурасы Президиумы әгъзасы итеп сайлана. Бер-бер артлы китапларын чыгара. Бу — аның унынчы китабы. Район халык театрының иң актив әгъзасы да була ул. Татарстанның атказанган мәдәният*

*хезмәткәре дигән мактаулы исемгә, әдәби уңышлары өчен Шәйхи Маннур исемендәге премиягә лаек була.*

*Вахит ага үз бизнесын да оештырып җибәрә. Кибет ача, умарталык булдыра.*

*Туган авылы Иске Комазанга Аллаһ йорты — мәчет салдыра. Мулланы да үзе табып, аңа йорт төзетә. Әби-бабалары, әти-әнисе күмелгән зиратны тимер челтәр белән әйләндереп ала.*

*Туры сүзле Вахит аганың авыр вакытларында күңеленә тынычлык бирә торган шөгыле бар. Ул шигырь яза. Шигырьләре аны рухландыра да, яшәтә дә, кайгы-хәсрәтләрен дә оныттыра. Иртән дә, көндез дә, кичен дә, җыелышларда да, утырышларда да яза ул. Кырда йөргәндә, илһамланып җырлый, халык җырларын күңелендә яңарта, үз җырларын да чыгара.*

*Бәхетле ир һәм ата да Вахит ага. Җәмәгате Наилә ханым белән 9 бала тәрбияләп үстерәләр. Алар — табиблар, укытучылар, хисапчылар. 26 оныгы һәм 6 оныкчыгы бар.*

*Вахит Галиев — татар халкының үзенчәлекле шагыйре, авыл шагыйре.*

*Бәхетле бул, яз, куандыр. Син үзең җир баласы булгандай, шигырьләрең дә табигать чишмәләре кебек гаҗәеп матур, ләззәтле, татлы, Вахит Вәли улы.*

***Әхмәт Гадел,***

*Язучы*

## *Мамадышым — бәхет калам*

Казан бәйрәм итә. Уртак бәйрәм.
Уртаклашам бәйрәм шатлыгын.
Тик шулай да күңелемдә теләк:
Мамадышта үтсен картлыгым.

Туган якның коры елгасы да,
Һәр куагы тарта күңелне.
Яратулар туган-үскән якны
Озынайтыр сыман гомерне.

Мин яратам чишмә-инешләрне,
Тәм табамын урман юлында.
Хезмәт сөйгән авыл, калам халкын
Мактап җырлап яшим җырымда.

Кем яратмас мондый гүзәллекне,
Сау-сәламәт булса йөрәге.
Мамадышым — бәхет калам минем —
Син бит безнең дөнья терәге.

Горурланам, калам, синең белән,
Ләззәт тоям, үтсәм урамнан.
Шөкер итәм сиңа, табынамын,
Ерак киттең үткән заманнан.

Сокландыра тигез асфальт юллар,
Урам саен үскән йортлар да.
Дөньябызны якты нурга күмгән,
Хөрмәт белән янган утлар да.

Без үскәндә ат арбасы баткан
Сазлы урам күптән онтылган.
Бүгенгесе — гүзәл. Шатландыра.
Киләчәге күккә омтылган.

* * *

Күңелемдә изге теләкләрем,
Юлларыңа синең гөл сибәм.

Күзләреңә карап туя алмыйм,
Йөрәгемдә кайнар ут сизәм.

Сөйләп булмый һәм күренми,
Хисләр буталалар күңелдә.
Әйтә алмыйча, эчтән генә шулай
Янармынмы икән гомергә.

Аңласаң да, белмим, нишләтерсең,
Су сипмиләр янган йөрәккә.
Бер мизгелгә дару булсаң иде
Ташып торган утлы теләккә.

## *Мәңге яшә*

Нократ елгасында су коендым,
Печәннәрен чаптым болында.
Кешелеккә гүзәл гөл үскәндер
Тәннән тирем тамган урында.

Яшәү чыганагы — тырыш хезмәт,
Җәмгыять тә үсми хезмәтсез.
Хезмәт сөймәс ялкау, әрәмтамак
Кешелектә яши хөрмәтсез.

Хезмәт куймый, үсми кырда икмәк,
Машиналар — хезмәт җимеше.
Чишмә хезмәтеннән тулып ага
Яшәр җирнең елга, инеше.

Шар сугасы урам малайлары
Хоккей уйный гүзәл сарайда.
Спорт белән мавыгырга мөмкин
Кичә чалбар кигән малай да.

Чагыштырып карау бик файдалы
Бүген белән үткән заманны.
Аера белер иде сукбайлар да
Яхшы белән явыз, яманны.

Мин яратам. Яратсыннар иде
Бар кеше дә үскән җирләрен.
Куансыннар, табынсыннар иде
Тәм, ямь табып туган илләрен.

Яшә, калам!
Мин — бер балаң синең,
Ташка кадак кагар теләктә.
Кешелеккә җылы бирү өчен,
Мәңге җылы саклыйм йөрәктә.

* * *

Март аеның җиләс җилкәйләре
Иркәләгән кебек кырларны,
Якты кояш сөеп елмайгандай
Хөрмәтлиләр хатын-кызларны.

Кешелекнең гүзәл чәчәкләре,
Дөньябызның күңел язлары,
Сездән башка тормыш дәвам итми,
Табып булмый иркә-назларны.

Бар кешелек сезгә башын ия,
Тормыш бирүчеләр — Аналар.
Дөньябызны гүзәллеккә күмә
Сез тудырган газиз балалар.

Бәйрәм таңы сезгә дан җырласын,
Чәчәкле яз тойсын күңелләр.
Сөю, сөелүләр, назлар белән
Озак дәвам итсен гомерләр.

* * *

Күп күрәбез орден, медаль таккан,
Түргә элгән хәрби киемнәр.
Дан җырлардай кием иясенең
Бик күпләре исән түгелләр.

Калганнарның сугыш кырларында
Киемнәре илгә кайтмыйлар.
Якташлары батыр егетләрне
Йөрәкләрдә данлап саклыйлар.

* * *

Бирер идем сезгә таң нурларын,
Сулар өчен урман һавасын.
Тел байлыгым туплап сайлар идем
Сүзләремдә йөрәк дәвасын.

Назлы матур сүзләр — дәва алар,
Мәхәббәте — Алла бүләге.
Сөю, сөелүдә үткән көннәр —
Кешеләрнең яшәү теләге.

Яшәсәгез иде борчылусыз,
Саф мәхәббәт тоеп күңелдә.
Еллар, көннәрегез үтсен иде
Бәхет, шатлык белән гомергә.

* * *

Гомер көзе. Гөлләр өзәм.
Өзә алмадым язымда.
Матур хисләр туа,
тәмле исләр килә,
Син булганда яннымда.

Күңелемдә кошлар сайрый,
Очасым килә күккә.

Җиргә төшәм димәс идем,
Син дә яшәсәң күктә.

Яңымнан китсәң, юксынам,
Син генә күңелемдә.
Хисләр ташый, төшенсә дә
Үземә түгелеңә.

Көлмә, таптама теләкне,
Хисләр белән уйнама.
Синең нурларда эрүне
Юләрлек дип уйлама.

* * *

Март җилләре шаяралар кырда
Яз җылысын сизеп, тоепмы.
Кайчагында буранлап та ала
Әллә суык кыштан туепмы.

Бик нык, каты торган бозлар да бит
Батырлыгын җуя, яз өргәч.
Җиңеләләр калын кар көртләре,
Чәчәкләргә тулган җәй килгәч.

Мактана алмый елның мизгелләре:
Кышы, җәе, язы, көзе дә.
Бер-берләрен алмаштырулары —
Табигатьнең сере үзе дә.

Табигый хәл. Еллар шулай уза,
Бик күп төскә бизәп күңелне.
Мизгелләре белән акрынлап
Алып китә безнең гомерне.

* * *

Тибеше үзгәрде йөрәкнең,
Көчләре әзәйде беләкнең.
Тамыры какшады үзәкнең,
Чокыры киңәйде кирәкнең.

Өметтә шайтанлык сизелә,
Йолдыз тотмак булып үрелә.
Күзләремдә утлы чаткылар,
Мае азайганмы, сүрелә.

Өмет итеп иркә назларны,
Көтәм әле килер язларны.
Сагышларга манып дөньяны,
Көтәм көзен киткән казларны.

* * *

Син бит миңа, иркәм, наз бирдең,
Утларымда, әйдә, ян, дидең.
Өзелеп сөйдем, утыңда көйдем,
Күңелемдә бердәнбер идең.

Гомерләр үтте, ялкыннар сүнде.
Алыштырдыларммы үзеңне?!
Кырын карап серле күзеңне,
Ник үзгәрттең икән сүзеңне?!

Язлар үттеләр, назлар беттеләр,
Суындылар никтер куеннар.
Гомернең тәме, яшәүнең яме,
Сүрелделәр тәмле уеннар.

* * *

Яшәү җиңел түгел кемгә дә,
Йөртә барсын түбән, үргә дә.
Гомер юлларыңа тау үссә дә,
Туктый күрмә, алга үрмәлә.

Дөнья яме, тәме көрәштә,
Әйдәкләгез алга, көрәшкә.
Җиңеп үтсәң, менеп җитсәң,
Исемең калыр мәңге — үлгәч тә.

Дөнья иркен. Кайчак юллар тар.
Күктә болыт. Ява яңгыр, кар.
Күңелеңнән белеп, күреп яшә:
Болытлардан өстә кояш бар.

* * *

Көзен киткән кошлар кайтыр вакыт,
Көтегез сез, дуслар, көтегез.
Яшәү мөмкинлеген уйлагызчы
Ямь бирердәй кошка үзегез.

Кем теләми матур кош тавышын,
Кем сокланмый килгән язларга?!
Баетырлар безнең табигатьне
Сыерчыклар, былбыл, казлар да.

Мөмкин түгел лә шул
Кошкайларга бездә кышларга.
Әзерләнеп каршыласак иде
Еракларга киткән кошларны.

* * *

Март, апрель — кышның курыкканы,
Җәйнең котын ала декабрь.
Февраль белән әгәр кыш мактанса,
Көз хозуры—алтын сентябрь.

Җәйнең гүзәллеге ялга тала,
Кыш салкыны — ак кар капласа.
Ә яз җиткәч, кышның явызлыгын
Агызырга җәй бит юл ача.

Үз урынында көчле һәр мизгел дә,
Уңайлысы була, киресе...
Кеше теләгәнчә генәмени,
Уңай булса да бит күбесе.

Канәгать бул, тиеш дип сана
Үзенчәлеген елларның.
Тормыш барсын, көе бозылмасын
Ләззәт бирер назлы җырларның.

## *Акылыңны тупла*

Тормыш таләпләре,
күңел дулкыннары
Утка кертә, сала диңгезгә.
Уңган бала һәрчак яшәү бирә
Ата-анасы корган нигезгә.

Арта бара, балда-майда үсеп,
Шешә җыючылар калада.
Әмма тырышлыгы җимеш бирә
Хезмәт сөйгән, эшчән балага.

Һич онытма нигез ташыңны,
Юньсезлеккә салма башыңны.
Матур булам диеп, эшләмичә,
Буяп йөрмә тырнак, кашыңны.

Бизәнергә мөмкин, бизәсәләр
Хезмәт нәтиҗәңне хөрмәткә.
Акылыңны тупла матур итеп
Кешеләрчә яшәү кирәккә.

## *Үпкәләмә*

Син кулыңны җәеп басып калдың,
Киткән чакта тауга мин менеп.
Аякларым тайса, юлларымда
Тора идең аста син көлеп.
Үргә мендем, шуып аска төштем,
Үрмәләдем кабат югары.
Түккән көчем әрәм түгел,
Яшәү омтылышым дөрес юл алды.
Нигез кордым, гөл бакчасы чәчтем,
Чәчәкләрем бирде җимешләр.
Оям булды чишмә, тулып акты
Кешелеккә кирәк инешләр.
Күп һәйкәлләр куйдым киләчәккә,
Уртаклаштым яшәү тәмемне.
Кирәк була калса, якташларга
Бирергә мин әзер җанымны.
Син һаман да тигез, йомшак җирдә
Таяк тотып казлар куасың.
Табигать бит, үзең яратмасаң,
Иркәләми адәм баласын.
Адашмадым йөргән юлларымда,
Җырларымда сагыш җырладым.
Күз алдымда бергә яланаяк
Сабан сөргән, сөйгән кырларым.
Үпкәләмә, кимсетүем түгел,
Бик иелмә мине күргәндә.
Тик үткәндә бераз хәтер калган

Жаның аңламастан,
Уйламыйча миннән көлгәнгә.

## *Элек алай түгел иде*

Элек алай түгел иде,
Әллә нишләде аяк.
Йә авырта, йә атламый,
Кулга тоттырды таяк.

Элек алай түгел иде,
Бетте назларга теләк.
Игътибар юк яшьләргә,
Теләп типсә дә йөрәк.

Элек алай түгел иде,
Юкка кием туздырам.
Күзгә кигән күзлегемне
Эзләп вакыт уздырам.

Элек алай түгел иде,
Кырау манган чәчемне.
Көзгедә күргәндәй булдым
Сиксәндәге яшемне.

Элек алай түгел иде,
Тәм таймый бит тәннәрем.
Сиксәнгә җиткән кешенең
Белмиләр шул хәлләрен.

Элек алай түгел иде,
Игътибар җитми язга.
Коръән сүрәсен кабатлап,
Шөкер итәм һәр таңга.

## *Язлар уяталар*

Яфракларын коя агачлар да,
Чәчәкләре шиңә гөлләрнең.
Байлыгы бар, тик саргайта барын
Ачы салкын җиле көзләрнең.

Язлар уяталар җан иясен,
Дөнья яшеллеккә күмелә.
Гөлләр белән чәчәк ата күңел,
Гомер мәңгелектәй күренә.

Язлар үтә, гомер яшьлегедәй,
Әкрен генә шиңә үләннәр.
Соңга калып, тирән көзне күрә
Тормыш кызуына түзгәннәр.

Салкын кышның явыз бураннары
Күммәсеннәр үтәр юлларны.
Гомер барсын, гөлләр чәчәк атсын,
Җырлыйк язын туган җырларны.

* * *

Яфракларын койган ак каеннар
Урман гүзәллеге бүген дә,
Салкын кышларына сыгылмыйча,
Горурлыгын саклый үзендә.

Ак каенның зифа буен күреп,
Горурланып китә күңелләр.
Урман гүзәлләре кебек яшәп,
Горур үтсен иде гомерләр.

* * *

Безне кешеләр сөйлиләр
Мактап та, яманлап та.
Парланалар дип сөйлиләр
Күреп тә, ялганлап та.

Парланса (кемгә начарлык),
Бергә күңел ачарлык.
Бар парлы гөнаһ ясамый
Кешеләрдән качарлык.

Шуңа исемә дә элмим,
Йөрим йөргән юлымда.
Күрмәгәннәр ишетсен дип,
Зурлап җырлыйм җырымда.

## *Сәер булыр микән*

Син булганда, җаным эреп китә,
Җиңеләя тәндә хәрәкәт.
Мин бәхетле, янда сине күрсәм,
Барсы өчен бик зур рәхмәт.

Бергә яшәп, белеп бетердек без
Уңай, кимчелекле якларны.
Алыштырдык,
тормыш таләп иткәч,
Машинага җиккән атларны.

Бергә таянабыз таякларга,
Аксап киткән чакта — нилектән?
Тормыш йөген тигез тарткангамы,
Тигез борчылабыз электән.

Еллар ала инде үзенекен,
Ала тәнебезнең сәләтен.
Борчылусыз көннәр сәбәп булсын
Озайтырга гомер сәгатен.

Туры килде, гомер кичергәндә,
Бик күп михнәтләр дә күрергә.
Сәер булыр микән, 100не үтеп,
Туры килсә парлап йөрергә.

## *Солдат тормышыннан мизгелләр*

Көчле яңгыр. Шәрә басып торам
Йөрү өчен коры киемнән.
Мин — яшь солдат, кием алышырга
Ерак идем туган өемнән.

Кием салынмаган ничәнче көн,
Йокысыз төн санын югалткан.
Вагон идәнендә тәмле мизгел
Урын табып җанны юаткан.

Беренче кат кулга мылтык тотып,
Япа-ялгыз торам мин сакта.
Шыбыр-шыбыр пыскып яңгыр ява,
Берни килми башка ул чакта.

Ялгызлык та шикләндерми бүген,
Яшәү тәмен ала ач карын.
Бер мәртәбә туя ашау өчен,
Сүз юк, алсалар да бар малың.

Гыйбрәтләр олы сабак бирә,
Кичергәндә ашый җаннарны.
Алла үзе сабырлыклар бирсен,
Тәндә яра боза каннарны.

Каешлана, тупаслана холык,
Яши-яши тәннәр искерә.
Гомер үткән саен, үзгәрүдән
Котыла алмый кеше һич кенә.

## *Артыгы юк*

Йөрәк өзгеч ачы җил сызгыра,
Тели тәнгә үтеп керергә.
Кара бураннарда мин көрт ерам
Бер мизгелгә сине күрергә.

Уй-фикергә ниләр генә килми,
Туймас нәфес таулар күчерә.
Тик табигать барын үлчәп бирә,
Юк, артыгын бирми кешегә.

Мин, мин, диеп үрмәләүләр
Мөмкинлеге түгел тәнеңнең.
Ул — тик эзе, йөрәгеңә сеңеп,
Бик еракта калган тәмеңнең.

Син орышма, әгәр очрашып,
Юк-бар сөйләп күңел табылса.
Артыгы юк, разый булсаң иде:
Дуслык хисе белән янылса.

## *Акланмады көткән өметләр*

Тарихчылар табып бетерә алмый
Батырларны сугыш елыннан.

Чиге булмады шул үтүченең
Канлы елның канлы юлыннан.

Ул елларны баскан һәр урында,
Эзләрендә йә кан, яки күз яше.
Кешелек бит яшәү белән үлем
Арасында түзеп яшәде.

Үрмәләде, тырмаланды җаннар,
Бар сәләтен туплап җиңүгә.
Нәтиҗәдә дошман каберлеген
Илтеп куйды чыккан җиренә.

Янган җирләр инде икмәк бирә,
Кабат үсте беткән калалар.
Тик кайтмады туган өйләренә
Ил сакларга киткән балалар.

Ач-ялангач, җиңү өчен диеп,
Илгә тупладылар барын да.
Киләчәге өчен олы өмет белән
Кешеләр бит бирде канын да.

Юк. Акланмады көткән өметләр,
Ипигә туйса да тамаклар.
Югарыга менеп булмады,
Гомергә көйделәр канатлар.

Кан, яшь түгеп саклап калган илне
Ваклап тараттылар сугышсыз.
Аерылганнар күбесе уңышсыз,
Яши алмый ярдәм, булышсыз.

Туганнарча бер казаннан ашап,
Бергә җиңүчеләр үлемне,
Бер-берләрен күрми, чит илләрдә
Дошманлашып яши түгелме?!

Гөрләп торган авыл җансызланды,
Ит, сөт, ипи чит-ят илләрдән.
Эшсезлектән наркоманнар туа,
Интегәләр башка чирләрдән.

Калаларга салган йортлар белән
Мактаналар кайбер түрәләр.
Авылларны бетерүне алар
Зур батырлык итеп күрәләр.

Илне талап байлык туплау чоры.
Бу — тарихның олы ялгышы.
Киләсе көн өчен җаваплымы
Җиңеп чыккан халык язмышы?

Юк, юк, акланмады көткән өметләр,
Әрәм югалдылар егетләр.
Түргә менеп, балда-майда йөзә
Илне саткан юньсез җирбитләр.

Гомер үтә, үтсә үтсен әйдә,

Бирешмәсен бик тиз картлыкка.
Борчылулар берүк читләп китсен,
Үтсен иде көннәр шатлыкта.

Сәбәп чыксын иде рухланып
Йолдызларга карап очарга.
Картлыкта да яшьлек хисе белән
Назга чумып, сөеп кочарга.

Чәчәкле яз, җиләк-җимешле җәй,
Уңышка бай көзләр килсеннәр.
Ходай насыйп кылып, гомерләрне
Бәхет тойгысына күмсеннәр.

* * *

Яңа яуган мамык карны ерам,
Сокландыра карның пакьлеге.
Бертуктаусыз борчып тора һаман
Күңелләрдә якты юклыгы.

Юк, канәгать түгел, сулыш җитми,
Үкенгәндәй туган көненә.
Көтмәгәндә кайнар су сиптең бит
Шаулап үскән күңел гөлемә.

Күңел нечкә. Бик нык нечкәртәләр
Ут төрткәннәр күңел базына.
Кырау өчен сәбәп тиз ясала
Көлгә күчкән гомер язына.

* * *

Илне саклап үлгән батырларга
Чит җирләрдә булды каберлек.
Шул корбаннар каны өчен дә бит
Булмады инде җирдә гаделлек.

## *Кара безнең заманга*

Айлы төннәрне күрдек, дөрес,
Караңгы төн сыман көннәрне.
Гомер буе кино итеп булмый
Алда карау өчен үткәнне.

Кара болыт, карлы-бозлы яңгыр...
Керер тишек тапмый урамда,
Биштәр киеп, җәяү юлда йөрдек
Кышкы салкын, әче буранда.

Без яшьлектә назлар күп күрмәдек,
Яшәү өчен җылы эзләдек.
Кара ипине дә, кайчан булса да бер
Туя ашарбыз дип йөрмәдек.

Мыек чыкканчы ук солдат булып,
Ач елаган солдат күргәндә,
Түзәсең шул, бомба шартлаганда,
Бер гөнаһсыз сабый үлгәндә.

Адәм баласы бит эт җаныдай,
Түзә, кичерә ул барын да.
Иң кадерле гомер, яшәү өчен
Йөзеп үтә кеше канында.

Әкият түгел,
болар — чынбарлык бит
Безнең буын — кеше язмышы.
Алгы буыннарга берүк килмәсә иде
Тарихларның андый язмышы.

Кешелеккә гелән нидер җитми.
Балда-майда йөзә, үзе зарлана.
Күрсәтәсе иде гыйбрәткә
Бармак төртеп безнең заманга.

## *Оныт*

Оныт тормыштагы кимчелекне,
Яман уйлар җилгә очсыннар.
Күңелләрне бәхет, шатлык бизәп,
Тәнне назлар сөеп кочсыннар.

Тигез түгел дөньябызда юллар,
Теләгәнчә түгел табигать.
Изгелекләр кирәк, тик онытмыйк
Үткәннәрдән алыйк гыйбрәт.

Хәрәкәтсез, башны түбән иеп
Утырсак без көн-төн догада,
Кушканнарны үтәмичә көтсәк,
Бу тугрылык булмас Ходайга.

Хәрәкәттә — бәрәкәт, диләр,
Хәрәкәтсез булмый изгелек.
Биргән гомер өчен шөкер итү,
Изге хезмәт кирәк иң элек.

Үзең эшләп аша, гадел яшә,
Хәрам кертмә тәнгә, ашыңа.
Хөрмәтләргә өйрән кешелекне,
Явызлыклар кертмә башыңа.

Оныт, әгәр юкка ачу белән,
Явыз борчу тулса күңелгә.
Изге эшләр калдыра алсаң җирдә,
Бәхет иясе син гомергә.

* * *

Син кимсенмә, нигә куналар, дип,
Бал кортлары, чебен, черкиләр.
Син — үзәктә тәмле исле чәчәк,
Бар да теләп сине исниләр.

Файдаланып синнән, бал җыялар,
Көч алалар синең тәмеңнән.
Акыллылар синнән тартыналар,
Пешәр сыман тоеп тәнеңнән.

Һич онытма, син — чәчәге гөлнең,

Чәчәкләргә куна сандугач.
Үзәкләрне өзеп елатадыр,
Йөрәкләргә кагылып сайрагач.

Тез астына сукса тормыш үзе,
Җилкә төшә, бөгелә билләрең.
Тормыш сүнә. Дәвам итмәс сыман
Алга табан яшәү эзләрең.

Саклый алсаң, кеше, сәләтеңне,
Яшәү бетми, үзең сүнмәсәң,
Чәчәк икәнеңне истән чөеп,
Өметсезлекләргә сеңмәсәң.

Көч тап, эзлә, һәр мизгелдән күзлә,
Күңелеңә җылы наз юкмы.
Сүндерергә сәбәп таба алырсың,
бәлки,
Йөрәгеңдә янган шул утны.

* * *

Кешеләр бит тәмләп чәй эчәләр,
Күзләп тора күңел күзләрем.
Чәй теләгән саен чәй эчәргә,
Чәй бүләргә сине эзләрмен.

Бик кечкенә мизгел йөрәк ашый,
Күңел тәмен бетсә, урланса.
Бик куркыныч авыр хәл ул
Чәй эчәргә кешең булмаса.

Яшә, бәгърем, яшә яннарымда,
Бергә чәй эчәргә генә булса да.
Бакчабызда кош тавышы моңлы,
Баскан ботаклары корса да.

* * *

Егет җилле, тик күлмәгем кыска,
Бөкерәйсәм — артым күренә.
Чама килми, тезләр дерелдиләр,
Тик нәфесем калды күземдә.

Юләр йөрәк шашып типкән була,
Якынлашса назлар иясе.
Күңел курка, телләр сөяксез бит.
Килә: «Мин бит әле», — диясе.

Картлык шатлык түгеллеген белә,
Ләкин күңел сүнми, тузына.
Тәннең хәле беткән, барын-югын
Куя алмый кирәк урынга.

* * *

Күңелемдә изге хис, хыяллар,
Бәхет чәчсәң иде тигезләп.
Һәркемгә дә яшәү бирсәң иде,
Шатлык тойгысына нигезләп.

Күзләрдә яшь, борчулы караш,
Төс, кыяфәт — мескен күренеш.
Сабый чакта бөреләнгән теләк
Үтәлмәсә, нинди үкенеч!

Һәр мизгелдән ләззәт, тәм эзләргә,
Баш имәскә буран булса да!
Су сип чәчәкләргә — җимеш бирсен,
Кайбер ботаклары корса да.

Файда бирми, әйбәт булам, диеп,
Кимчелеккә исәң башыңны.
Һич онытма,
әйбәтнең дә авызыннан
Алачаклар ашар ашыңны.

## *Бәйрәм бүген*

Бәйрәм бүген — яшьле шатлык назлый,
Корбаннарны уйлап көенәм.
Оныткандай канлы, утлы юлны,
Исән калганыма сөенәм.

Бомба шартлаганда,
мин — яшь малай —
Берничә кат качтым үлемнән.
Үлем йөге төяп, тәре таккан
Самолетлар очты күгемнән.

Нинди мәхшәр — шартлау, йортлар яна,
Кемдер ава, кемдер йөгерә.
Балчык күмеп, танк таптап, күпләр
Калды кайталмыйча өенә.

Эт, мәчене, кош баласын жәлләп
Иркәләгән адәм баласы.
Йөз, меңләгән мәетләрне күрү
Калдырмыйммы йөрәк ярасы?!

Еллар сүндерә йөрәк утын,
Оныттыра бераз мәшәкать.
Төшләремә кереп саташтыра
Сугыш дигән явыз-кабахәт.

Бәйрәм бүген. Барын искә алып,
Еласам да, шатлык кичердем.
Кешелеккә ирек яулап биргән
Җиңү таңын искә төшердем.

* * *

Без кичергән шаулы ул елларның
Могҗизалар биргән һәр көне.
Яшәү белән үлем арасында,
Кылда йөргән кеше гомере.

Балчык янган, кеше исән калган,
Яшәү көче биргән үләннәр.
Карт-карчыклар, сабый балалар да

Барыр юлда арып үлгәннәр.

Сыер җигеп, илгә икмәк өчен
Ач-ялангач сабан сөргәннәр.
Ут эчендә җәяү Берлингача
Җиткәннәр бит һәм дә җиңгәннәр.

Дошман көчле,
җиңелмәстәй булган,
Таптап үткән иде күп илне.
Хром итек таптый алмый икән
Чабатадан йөргән чын ирне.

Үлем иләгеннән исән калып,
Җиңү көнен бәйрәм иткәндә,
Еласаң да бәхет. Шатлык җиңә,
Сөйгәнеңне кайтып үпкәндә.

Данга күмгән заман кешеләре
Көч бирерләр алгы буынга.
Ал чәчәкле Май гөлләре мәңге
Оныттырмас җиңү турында.

* * *

Сагындыра инде үткәннәр,
Яшьлек тәме белән үпкәннәр.
Бар да без теләгән төстә, күләмдә,
Килмәде инде, килми көткәннәр.

Кешелекнең кимчелеге, каһәр,
Нәфес бутый күпчак күңелне.
Булган байлык, тәмнәр аз тоела,
Канәгатьләндерми гомерне.

Ач чагында иң кирәге — ашау,
Чабата да кием — шәрәгә.
Салам кибәне дә — җылы кочак,
Йорт-җир юкта якын-тирәдә.

Булган саен ашау күп сайлана,
Түбә кирәк була алтыннан.
Юк чагында моң-зар ишетелә
Баласыннан, ирдән, хатыннан.

Дөнья шулай, яшәү бик катлаулы,
Бөтерә дә селтәп төкерә.
Кырык төскә кереп яшәтә дә,
Сайлап тормый — барын үптерә.

Барын аңлап, акыл белән яшик,
Язмышлардан ләззәт, тәм табып.
Без кунакта, кунак гомерендә
Мөмкин кадәр яшик ямь алып.

* * *

Синнән башка ямь табалмыйм һич тә,
Юксынудан шиңәм, сүреләм.
Исең, җилең кагылып киткәндә дә,
Сабыйларча ихлас сөенәм.

Бәйрәмнәр
Һич шатлык бирә алмый,
Син булмасаң минем янымда.
Буранлы кыш белән тиңләшәләр
Чәчәк бирер яшел язымда.

Борчылулар, бәлки, яшәтәдер,
Килә күккә биек менәсем.
Үрелергә буем җитмәгәндә,
Югарыдан килә күрәсем.

Бу — чир бугай, гел күрәсе килү,
Йогышлысы түгел, күрәмсең.
Теләкләрең чынга ашмасалар,
Барыр юлың юкка түзәсең.

Язмышларга ялгыш кертмәү өчен
Чикләнәдер, бәлки, теләкләр.
Көтә, түзә, тик борчыла никтер,
Үзенекен эшли йөрәкләр.

Гафу ит син, тик онытма гына,
Синең белән көтәм таңнарны.
Синең белән генә күрә алам
Чәчәкләрдән торган язларны.

* * *

Бәйрәм бүген, бар да бәйрәм итә,
Мин утырам өйдә ялгызым.
Вакыт тапмый, алларыма ятмый
Минем көткән иркә явызым.

Мөмкин булып, яннарыңда тотып,
Назла, назлан идең гомергә.
Гомер үзе озынаер иде,
Шатлык тулып йөрсә күңелдә.

Чарасы юк, сызланса да йөрәк,
Могҗизалар инде булмаслар.
Йөрәк өмет иткән, күңел көткән,
Без теләгән таңнар тумаслар.

Үкенечле язмыш бездә генә түгел,
Йөрәк яралары күпләрдә.
Бәхетләрен эзләп, беркем дә бит
Җирдән менеп китми күкләргә.

Алла акыл, сабырлыклар бирсен,
Өзелмәсен өмет, көткәннәр.
Морадына ирешәләр, диләр,
Акыл белән сабыр иткәннәр.

Минем чирем утлы мәхәббәттә,
Йоктырасы иде берәүгә.
Ике теләк бергә янар булса,
Гомер үтмәс иде әрәмгә.

* * *

Гәзиткә белдерү бирәм,

Эзләп йөрәккә дәва.
Эзләгәнемне табалмыйм,
Бу бит күңелгә җәза.

Суга кибеккәнең булса,
Аңларсың минем хәлне.
Сине эзләп, күрә алмыйча
Үткәрәм мин җәйләрне.

Минем өмет мулдан түгел —
Җитә назлы карашың.
Чәй эчсәк бергә утырып,
Ала йөрәк дәвасын.

Аңла, сакла йөрәгемне,
Юкса яралы калыр.
Караңгыда кара төсне
Эзләүләре бик авыр.

Теләк булса, вакыт була
Дару кабул итәргә.
Теләк юкта сәбәпләр күп
Эндәшмичә үтәргә.

Зинһар, сәбәп эзли күрмә,
Тырыш дару бирергә.
Мизгелләр тап дару булып
Яннарыма килергә.

## *Сәләт кирәк*

Ташкүмерне агартырга теләп,
Ышкып, кырып, юып карадым.
Күмер бетте, ләкин агармады —
Күпме мәгънә үзем аңладым.

Эче кара булган — һич агармый,
Черек булса көтмик ныклыгын.
Кешеләргә балта биру нигә,
Күрә торып кулы юклыгын.

Бар кешеләр — үз сәләтен белми,
Күп урынга тыга борынын.
Сәләтсезләрне бит борын хурлый,
Бәяләми алган урынын.

Эшкә куючылар белсә иде:
Өйрәнмичә оста булмыйлар.
Ат күрмәгән атка менсә дә бит,
Тиз егылып, үзен хурлыйлар.

Кыскасы шул: борын олы булу
Күрсәткече түгел сәләтен.
Изгеләнгән булып кыйланса да,
Әрәм итә гомере сәгатен.

* * *

Җитәкче дә, батырлар да — бар да
Синең алда башын ияләр.

Ап-ак чәчле әби-бабайлар да:
«Минем укытучым», — дияләр.

Укытучым! Зурлап башым иям,
Зур хөрмәтем саклыйм күңелдә.
Әйткән вәгазьләрең, киңәшләрең
Юлдаш булды миңа гомергә.

Гомер буе йөрттем үзем белән,
Яшәү өчен сүнмәс көч алдым.
Горурландым синең исем белән,
Кыек бассам, синнән оялдым.

Кичер мине, әгәр кайбер чакта
Син дигәнчә яши алмасам.
Төзәтермен, апа, соң булса да,
Кайда ялгыш барын аңласам.

Һәр укучың, синең үз балаңдай,
Шатлык, борчылулар бирәләр.
Халык та бит уңай, киресен дә
Сезгә әйтә, Сездән күрәләр.

Батырларны мактап сөйләгәндә,
Сезгә атап, гөлләр чәчәләр.
Кеше язмышларын бәйләп, Сезгә
Багышлана бик күп кичәләр.

Сугыш кырларында батыр булса,
Космонавт булса берәүләр,
Әйтү авыр, ләкин әйтми булмый,
Хулиганнар, каһәр, күбәүләр.

Алкаш, ятим, толлар, явызлар бар,
Чүп үләннәр сыман басуда.
Беләм, Сезне борчый, ләкин хаклык —
Укучылар булган барсы да.

Зур агымнан кергән ләмне җирдән
Чистартырга кирәк, туганнар.
Бик катлаулы заман, авыр һаман,
Күзгә керә кайчак тузаннар.

Тик шулай да Сезгә хөрмәт белән
Таләп көчле үскән заманда.
Элеккечә, «Укытучым» диеп
Тезен чүгә халык һаман да.

Бик зур өмет Сезгә багышлыйбыз,
Кергән чакта олы мәйданга.
Илдә булган кимчелекне бүген
Төзәтмиләр килеп кайдан да.

Саулык бирсен Ходай Сезгә,
Чынга ашсын изге теләкләр.
Үсәр буын гүзәл шытым бирсен,
Борчылмасын өчен йөрәкләр.

* * *

Мин — комиссар,
политхезмәтчемен,
Юлда тәгәрмәчем шартлады.
Язмыш үзе, астын өскә куеп,
Үтмәс итеп юлны каплады.

Яңа юллар эзләп тар сукмактан,
Озак йөрдем кырда адашып.
Туган якның чишмә, инешләрен
Күрә идем төштә саташып.

Нужа бабайларны сыртка салып,
Мин кайтканда туган ягыма,
Утсыз йөрәк үзен тоя иде
Яшәү белән үлем ярында.

Тырмашулар юкка булмадылар,
Үрмәләдем үргә — биеккә.
Су басмады, мөмкинлекләр бетте,
Санадылар кыргый киеккә.

Матур язлар кире кайтмаса да,
Гомер көзем бик бай җимешкә.
Тормыш тәмен кабат эзләп таптым
Яшьли йөргән чишмә, инештә.

Юлда калган ярык тәгәрмәчем,
Шөкер итәм, күптән ямалды.
Көзге гөлләр дәвалады сыман
Яшьлегемдә алган ярамны.

## *Әниемә*

Гафу ит син, әнием, рәнҗемә,
Һич тигезли алмыйм дөньямны.
Таплый күрмә берүк йөрәгеңдә
Миңа дигән хәер-догаңны.

Кайнар йөрәгемнең иң түрендә,
Газиз әнием, синҗа хөрмәтем.
Чуанлы тән белән башкарыла
Яшәү өчен кирәк хезмәтем.

Теләгәнчә генә бармый гомер,
Өстерәр йөк авыр арбамда.
Ана кочагына качып булмый,
Йөрер хәлләр бетеп арганда.

Исән чакта, соңгы тәмле ашым,
Үзем капмый, сиңа бирермен.
Бик кирәктә, арбам юлда ташлап,
Синең янда биеп йөрермен.

Белсәң иде сиңа күңелемдә
Изгелектә генә теләгем.
Гафу ит син, көчем җитмиенчә,
Үтәмәсәм күңелең таләбен.

## *Юк, зарланмам*

Бүген минем канат, имгәнгәндәй,
Аралашмый, сеңгән почмакка.
Күңел —
борчылудан көчле дулкыннарда,
Йөрәк — кайнар утлы учакта.

Сәбәпләре әллә нидә түгел,
Сагыш борчый җанны, йөрәкне.
Әниләре өчен, сабый сыман,
Өзәләр бит юкка үзәкне.

Уйлап утырам да гаҗәпләнәм,
Бер мәгънәсез санап теләкне.
Күп уйласам, йокысызлык борчый,
Акыл саклый алмый йөрәкне.

Тәэсирләнеп әсирләндем инде,
Башым иеп булган язмышка.
Юк, үкенмәм сөя белгәнемә,
Юк, зарланмам башка ялгыш та.

* * *

Ихлас күңел, кайнар йөрәгемнән
Сезгә саулык, бәхет теләдем.
Тәбрикләргә яшьлек туегызны,
Матур, йомшак сүзләр эзләдем.

Мәхәббәт ул —
Алла биргән бүләк,
Зур игътибар белән саклагыз!
Ихлас тугрылыкны,
биргән вәгъдәләрне
Гомер юлыгызда аклагыз.

Суынмасын мендәр, одеял эче,
Гаеп эзләмәгез юк-бардан.
Мәхәббәт ул тора изгелектән,
Алла саклый күрсен яманнан.

Гомер итү зур көрәшләр сорый,
Үрләре бар, үтмәс киртәләр.
Бердәм, тату гаиләләр генә
Гомер көзен бәйрәм итәләр.

Гомер көзе тигезлектә килсен,
Шатлык төяп тусын балалар.
Зур горурлык белән мактансыннар
Сезне үстергән ата-аналар.

## ***Рәхмәт, авылдашлар!***

Йөрәк хәлен алып тузынганда
Кызу кояш, көчле яңгырлар,
Янып яши хезмәт учагында
Тирләп пары чыккан авыллар.

Искән чакта әче салкын җилләр,
Өргән чакта әче бураннар,
Икмәк өчен, ит, сөт, май булсынга
Көчен сала тырыш-уңганнар.

Мин авылга дан җырлыймын һәрчак,
Авыл хезмәтенә табынам.
Чәчәк исле яшел язларыдай
Кар-буранлы кышын сагынам.

Хөрмәтлимен күңел түрем белән
Йөрәгемнең иң саф җиреннән.
Ләззәт табам ипи исе килгән
Авылларның назлы җиленнән.

Күз алдымда шаулап үскән икмәк,
Исен сизәм түккән тирләрнең.
Пешкән күмәч сыман парын күрәм
Сез эшкәрткән мамык җирләрнең.

Күпме хезмәт киткән җылы сөткә,
Ул менгәнче әле табынга.
Терлекченең хезмәт батырлыгы
Нур, дан бирә бүген авылга.

## *Кайт тизрәк*

Кайт тизрәк, җиләк бирәм,
Җиләктә йөри күңел.
Җиләкләр дә синнән башка
Ашарга тәмле түгел.

Җиләккә дип чыгып китәм,
Үзем гел сине көтәм.
Мөмкин булса, беркая да
Җибәрмәс идем бүтән.

Бер-берләреңнең кадерен
Белмисең бергә чакта.
Син киткәч, көннәр сүрелде,
Бар фикер синең хакта.

Кайт тизрәк яннарыма,
Үзең кирәк дәвага.
Аңла, синнән башка җитми
Сулышыма һава да.

## *Янып китә алмадым*

Ут кабынды, янып китә алмадым,
Пыскып кына янә сүрелдем.
Язмыштагы шундый мизгелгә мин
Эчтән генә бары сүрелдем.

Бик сөясем килде, мөмкин түгел,
Зарыксам да киттем борылып.
Борчылсам да, рәхмәтле идем

Киткәнеңә миңа орынып.

## *Мең рәхмәт*

Күзләремнең язы озын булсын,
Күзләр килер инде берзаман.
Ә бүгенгә, шөкер, өмет яши,
Кыска язлы күзләр бик яман.

Хыялланмый җансыз яшәү яшәүмени,
Борчыл, тәм тап, эзлә кирәген.
Яшьлегемә кайтып, газаплары белән
Янып сөю һаман теләгем.

Бик яшисем килә озак итеп,
Сәбәп эзлим гомер сузарга.
Ялкын биргәннәргә,
сөя белгәннәргә —
Мең рәхмәт әйтәм шуларга.

## *Юлларыма маяк кирәк*

Йөрәгемә әллә кан саудымы,
Бик атлыйсы килми аякның.
Барыр юлларымны таба алмыйм,
Кирәклеген тоям маякның.

Олы юлда алга омтылырга
Күңел тарткан көчләр кирәк шул.
Рухи байлык бирер дәлил булса,
Җиңеләя яшәр, барыр юл.

Үзем генә беләм сәбәпләрен
Нигә кысылганын йөрәкнең.
Яна, көя, сагышлана —
дәвасы юк
Акылыннан шашкан теләкнең.

Өмет яши. Бар да яхшы булыр,
Маяк булыр барыр юлыма.
Көннәр үтә. Җан җылысы биреп
Кушылырлар йөрәк җылыма.

## *Юксыну*

Сандугачлар тынды, син дә киттең,
Үзгәләнеп калды үзәгем.
Сагышларга чумган, урын тапмый,
Таш түгел шул минем йөрәгем.

Яшәү өчен тәм дә, ямь дә кирәк,
Син — йолдызы икән күгемнең.
Йолдыз сүнсә, караңгылык баса,
Эчке нуры бетә күңелнең.

Рухланган күңел канат яра,
Очмак булып яши һавага.
Синең үзең, күзең, сүзең кирәк
Янган йөрәгемә дәвага.

Өзгәләнеп көтәм. Җылы кирәк.
Үзем барсам, сыймыйм чамага.
Бөтен дөнья көләр, серләремне
Чыгып чәчеп йөрсәм далага.

Күңелемдә урын түрдә синә,
Ай, йолдызлар булып каласың.
Белеп, аңлап яшә йөрәгемнең
Синнән башка пыскып янасын.

* * *

Без үскәндә, кысыр җир калмады,
Арык атлар сөрде сабанны.
Чүп үләннәр басты басуларны,
Хурлап техникалы заманны.

Кем аңлатыр: нәрсә булды илгә,
Ничек ипи артты табыннан?
Гомер буе илне туендырган
Халык күчеп китә авылдан.

Балта, пычкы белән салган йортлар,
Кирпеч, таштан корган сарайлар —
Барын сатып кесә тутырдылар
Читтән килгән җансыз агайлар.

Техниканы, тимер ватыгы итеп,
Килмешәкләр илтеп саттылар.
Җир астына салган торбаларны
«Сам»нар түгел, «зам»нар таптылар.

Урыннарда хуҗа юкка чыкты,
Күп техника шуды әрәмгә.
Яхшырагы калды өй янында,
Майлы калҗа — юньсез адәмгә.

Үзәктәге хаким үзе өчен
Олыракны юллап йөргәндә,
Авылларны талап, таратканга
Сүз әйтмәде белгән, күргәндә.

Кулакларны илдән сөргәч тә бит
Җиргә чын хуҗа булдылар.
Исәннәре, соңгы хәлне күреп,
Урамнардан елап уздылар.

* * *

Борчыма юк-бар сүз белән,
Рухландыр мине күз белән.
Яшәү ялкыннары бирәм дисәң,
Каршы ал син көләч йөз белән.

Сине күрү — үзе зур бәхет,
Эчкә тула кояш нурлары,
Йөрәгемә — яшәү ялкыны,
Күңелемә — сөю җырлары.

Сата торган булса хисләрне,
Бәя табалмаслар күренсә.
Яшәү яме, тәме бетәчәк
Шул хыяллар әгәр сүрелсә.

Мин бәхетле: янам төтенсез,
Рухланып бирәм бар көчем.
Рәхмәт әйтәм мең кат сиңа
Сөйдерә белгәнең өчен.

Сөю бит ул — үзе бер талант,
Яңарсын кабат-кабат.
Җан биргәндә кычкырырмын,
Синең исемеңне атап.

* * *

Очарга дип канат кагынганда,
Кара болыт басты һаваны.
Теләк юлда калды, йөрәк янды,
Үзем генә белдем газапны.

Барыр юлларыңа буран чыкса,
Авырайта барыр юлыңны.
Рухланыр кешең көч бирмәсә,
Җырлап булмый сөю җырыңны.

Үз үлчәвең табу җиңел түгел,
Бар яктан да килми таләпләр.
Тел өйрәнеп марҗа эзләгәндә,
Очрый бит әрмән, гарәпләр.

Туры килеп, эзләгәнең тапсаң,
Кадерен бел, сакла, югалтма.
Күңел түрендәген рәнҗетеп,
Ятлар белән күңел юатма.

* * *

Үпкәләтмә, күпме мөмкин көтү
Тәннәремә кирәк дәваны.
Нигә дәваларга уйламыйсың
Сагышлардан алган яраны.

Теләгәннәр һәрчак эш күрсәтә,
Сәбәп эзли җаны үлгәннәр.
Тамчы канын биреп уртаклаша
Кеше хәлен аңлый белгәннәр.

Аңлыйм сине — барысыннан гарык,
Кирәк түгел тәмле җимешләр.
Баю җиткәч, адәм балаларын
Кызыктырмый алтын-көмешләр.

Бу дөньяда акыл ияләре
Кешеләрне зурлый беләләр.
Бик юньсезләр генә, булдырам дип,

Дусларыннан кайчак көләләр.

Берүк көлмә, аңла теләгемне,
Яшәү ямем, тәмем синдә бит.
Чын йөрәктән әгәр яналмасам,
Син дигәнчә яшим нигә дип.

Сакла, яшәт, һич тә ялган кертми,
Күздән аңла нәрсә кирәген.
Гөлләреңә су сипкәндәй кылан,
Юкса беркөн шиңеп китәрмен.

* * *

Бик теләсәң, тау тишәсең,
Таш ватасың баш белән;
Йөрәгеңә якын дусларыңны
Хөрмәтлисең тәмле аш белән.

Сине беләм, күрәм урман аша,
Шуңа борчу минем күңелдә.
Теләсәң бит көннәр өстәр идең
Озын язлы минем гомергә.

Киттең, кайттың, мин риза инде
Күңел бакчаң гөлгә күмелгәч.
Аңлыйсыңмы, күпме тәм югала,
Миндә утлар пыскып сүрелгәч.

Төшенмәгән сыман читләшәсең,
Уйламыйсың булган чынлыкны.
Күпме мөмкин сындырмыйча саклау
Кылдан нечкә теләк-чыбыкны.

Мескен түгел, жәллә диеп әйтмим,
Көлмә генә минем теләктән.
Сусавымны күптән басар идең,
Сагынып кайтсаң мине йөрәктән.

## *Бәхетсезлек*

Баудан йөри берәү егылмыйча,
Тыныч йоклый ятса урынга.
Малга табынганнар йоклый алмый,
Азынганнар акча турында.

Абыналар тигез асфальт юлда,
Хәрам кыса күпчак сулышын.
Кирәгеннән иртә һәлак була,
Туктата алмый эчке сугышын.

Алган яза — маллар кала бар да,
Хөрмәт бетә фани дөньяда.
Байлык оныттырган изгелекне,
Беркемгә калмый хәер-дога да.

Әле генә таптап йөри иде
Төкереп ул кеше башыннан.
Күпләр күреп качып кала иде

Йөрәгендәге каты ташыннан.

Таш эреде. Ләкин бик соң инде,
Керә алмады кабат рәхәткә.
Бар малын да җилгә атар иде
Яшәр өчен дуслар кирәккә.

Төннәр буе акча санап кына
Нинди мәгънә яшәү дөньяда?
Бәхетсезлек изге гамәл кылмый,
Мохтаҗ кала хәер-догага.

## *Куркам*

Мин шикләнәм сине атарлар дип,
Жәлләп түгел, куркып үземнән.
Кешеләрдә нәфрәт уятасың
Кыргый, явыз, усал сүз белән.

Күп талыйсың оялуны белми,
Эш урыны хәзер — акчага.
Синең корсак туяр төсле түгел,
Акча елга булып акса да.

Халык — сарык түгел, ялгышмагыз,
Күрми, белмиләр дип йөрмәгез.
Өйрәнегез кеше хөрмәтләргә,
Барсына да эттәй өрмәгез.

Бик атасым килде бер мизгелдә,
Юк, атмадым уйлап сәләтен.
Атарлар дип көтәм, ләкин куркам
Миннән күрерләр дип сәбәбен.

Миндә булган фикер башкаларда
Булмас диеп уйлау ярамый.
Яраланган йөрәк сине атуны
Гөнаһ булыр диеп санамый.

Ал кулыңа Коръән Кәримебез,
Иман яңарт алгы юлыңа.
Акча белән гомер алып булмый,
Калыр малың этләр кулына.

## *Юләрме?*

Юләрлегемне үзем дә бит беләм,
Ялгыз чакта барын уйлап көләм.
Юк, зарлану түгел, файда күрәм,
Алгы юлларыма гөлләр тезәм.

Саулыктан да кыйммәтниләр бар соң,
Сау булганда, гомер өметле.
Сау мин бүген диеп уйлап йөрү
Ныгыта бит яшәр өметне.

Миннән көлеп авыз чайкасалар
40 — 50 яшьлек бабайлар,
Миңа маяк алда яшәү өчен

100 гә җиткән эшчән агайлар.

Канат ярам, эзләп җирдән чабам
Рухи байлык бирер юләрне.
Үпсә-кочса, иркә-назлар бирсә,
Шуңа ирешкән кеше юләрме?

* * *

*(Яшьтәшем Хаммат истәлегенә)*

92 гә җитәсең, дип,
Чегән алдады, каһәр,
Яшәп булмады дөньяда
Хәтта 80 гә кадәр.

Бар да калды, казганганнар,
Гел буш китте кулларым.
Дәвамым булып калдылар
Кызларым һәм улларым.

Рәнҗергә сәбәпләр юк,
Мамык булсын балчыгым.
Хәер-догамның олысы
Сиңа инде, карчыгым.

Балаларым, пакь булыгыз,
Яшәгәндә дөньяда.
Сезне мактаса кешелек,
Дога булыр миңа да.

## *Онытма*

Аерылабыз менә тагын,
Ай булмаса да, шактый.
Аерылу гомер кыскарта,
Күрешү аны саклый.

Юксыну — сагыш инде ул,
Төшенсәң иде барын.
Синсез миңа көн караңгы,
Уйлап йөр шуны, җаным.

Көтәрмен санап көннәрне,
Сәгатьнең минутларын.
Онытма җирдә мин барын,
Юк, мин дә онытмамын.

Тыңламам инде кошларны,
Тынарлар син югында.
Сине озатсын кошларым,
Гөлләр үссен юлыңда.

## *Насыйп ит*

Килә һәркем бу дөньяга,
Кунак гомер тиз уза.
Кием-салым гына түгел,

Кеше тәне дә туза.

Чәч агара, тешләр төшә,
Бу — хәбәрдер китәргә.
Кем теләми яшәгәндә
90 га һәм 100 гә җитәргә.

Язмыштан узмышлар булмый,
Белеп булмый язмышны.
Бер Ходаем, үзең сакла
Кылдырудан ялгышны.

Яшәгәндә, изгелекне
Эшләсәк иде мулдан.
Киткәндә, Ходаем,
насыйп ит
Китәргә изге юлдан.

## *Өмет сүнмәсен*

Кыйбласыз заман, син эшлисең һаман,
Колхоз менә алмый үргә табан.
Дәүләтнең сездән кул селтәве яман,
Тереләсез шушылай барса ялан.

Колхоз бетәр, авыл нишләр икән,
Ана телен онытмабыз микән?
Авылларга игътибар юк нигә икән,
Ашау өчен теләк бетте микән?

Алла саулык бирсен, юнь табылыр,
Белеп булмый, бәлки, ут кабыныр.
Дөнья бутар юньсез көч алыныр —
Авыл өчен һич көтмәгән җай табылыр.

Сабыр итү — сары алтын, диләр,
Табыла бит җырга һәрчак көйләр.
Ничек булганлыгын тарих сөйләр
Безнең йөрәкләрдә бүген.

Һәр заманның була батырлары,
Табылалар көмеш, алтыннары.
Өмет итик бай, мул табыннарны,
Тик сүнмәсен йөрәгеңнең ялкыннары.

## *Ишетмиләр минем тавышны*

Минем тавыш иң көчлесе түгел,
Ишетмиләр минем тавышны.
Этлеге өчен судка бирер идем
Иң беренче яшьли танышны.

Йомшак, матур, серле теле белән
Берне сөйли, эшли киресен.
Бүген талый, кешелектән кәлә,
Нәфес туймый, ансын күрерсез.

Һәрнәрсәнең кыры, чиге була,
Шартлый шарлар артык өргәндә.
Хәзер инде күпләр
корал кармалыйлар,
Ул юньсезне читтән күргәндә.

Гөнаһысы әгәр ачыкланса,
Күз яшьләре күле күренә.
Тимер читлек кенә саклар аны,
Явызлыгы әгәр беленсә.

## *Кем теләмәс*

Йөрәгемдә минем нурым сүнде,
Сагышлардан җаным борчыла.
Мөмкинлеге югын белсә дә бит,
Күңел синең янга очына.

Борылам да карыйм артларыма,
Сагынмаска эзләп сәбәпләр.
Сәбәпләр тизрәк үтсен инде,
Бу — вакытлы авыр сәгатьләр.

Картайгач та, күңел — хыялларда,
Бәхеттер ул — янса учаклар.
Кем теләмәс гомер мизгелендә
Яшьлегенә илтәр кочаклар.

Гаепләмә, юләр сыман тоеп,
Сиңа булган күңел хисемне.
Тәмле итеп көнгә мең кабатлыйм
Йөрәгемдә синең исемне.

## *Кайт тизрәк*

Туйганчы үбә алмадым,
Тиз киттең яннарымнан.
Йөрәк ялкынсынып калды
Синең биргән назларыңнан.

Йөргән сукмаклардан эзлим
Хәзер синең эзеңне.
Күрергә юксынып йөрим
Синең көләч йөзеңне.

Сандугач тынды күңелдә,
Кояш сүнде күгемдә.
Сагышлы, ямьсез көнемдә
Бер син күңел түремдә.

Кайт, бәгърем, кайт тизрәк,
Газапланмасын йөрәк.
Җиргә дәртсенеп басарга
Син янда булу кирәк.

* * *

Сугыш елы сабые һәйкәлен
Манар идем чиста алтынга.
Исән калган, җиңгәннәре өчен
Исемнәре мәңге калсынга.

Сугыш кырларында —
балчык, тимер,
Бар җан иясе утта янган.
Газраил канат җилпегәндә,
Сирәге генә исән калган.

Ач-ялангач яшәр көчен тапкан,
Ат урынына «уфалла»сын тарткан.
Бар тапканын илгә озаткан,
Тамагына үлән табып капкан.

Дөньякүләм кешелеккә авыр заман,
Бүген, шөкер, яшәү ямен табам.
Яшьлегемдә калган тирән ярам
Йөрәкләрне тырный һаман.

* * *

Көннәр буе тулгак көттем,
Аптырады кешеләр.
Мине, шөкер, читләп үтте,
Сызланды, ахры, күршеләр.

Көткәнең булса уңайдыр,
Сызламас иде йөрәк.
Бик рәхәт түгел инде,
Үтәлмәгәндә теләк.

Сызланмасын йөрәкләре
Үз иткән кешеләрнең.
Янсын, корсын әгъзалары
Тулгаклы күршеләрнең.

* * *

Теләк, хыял, нәфес сүнмәсә дә,
Еллар кысты йөрәк тибешен.
Алыр сыман барын кире кайтып
Яшьлегеннән калган тиешен.

Ләкин гомер кабатланмый,
Беркемгә дә кире кайтмый борылып.
Тормышның тәмен ал син тулысынча,
Ашык, йөгер, йөрмә сугылып.

* * *

Кытыгым да, ачуым да килми
Минем арттан куа килгәнгә.
Син дә бер дә үпкәләмә, дустым,

Сөйләшкәндә «картлач» дигәнгә.
Тик бел шуны: 60 — сүнү түгел,
Ул — яшьлекнең генә картлыгы.
Иншалла, насыйп булыр әле
100 яшьтәге бәйрәм шатлыгы.
Мин ышанам, 60 — яшьлеге ул
Озак, озын килгән картлыкның.
Карыйм, бүген күрәм тантанасын
Сиңа хезмәт биргән шатлыкның.
Сөбханалла, сизәм, тиреңкалын,
Сөякләр нык, корыч-тимердәй:
Халык өчен зур күрсәткеч яулап
Чаба-чаба эшләп йөрердәй.
Синең үткән хезмәт юлың бөек,
Ераклардан күрәм нурларын.
Сиңа саулык, изге теләк бөркеп,
Яңгырасын бүген җырларым.
Күңелемдә изге теләкләр күп,
Ача алмам, бәлки, барын да.
Йөрәк җылым саклыйм,
тапшырырмын
Йөздән арткан бәйрәм язында.
Тәбрик итәм,
Кызык булыр төсле
100 дән үткәч җырлап йөрүе.
Теләгем бер: насыйп булсын сиңа
Шундый кызыкларны күрүе.

## *Килер соңгы таңым*

Һәр таң миңа бәйрәм булып туа,
Күрәм кыйммәтлеген гомернең.
Саргайтмаска телим яфракларын
Яшәү тәмен белгән күңелнең.

Канатларым зәгыйфьләнгән сыман,
Очарга дип бакмыйм күкләргә.
Ләкин җирдә бик күп гөл үстерәм,
Яшәү нуры сирпер күпләргә.

Шөкер, Ходам биргән мөмкинлеккә,
Шөкер, якты дөнья нурына.
Шөкер инде, соңгы минутымда
Шатлык хисе кушсам җырыма.

Белеп яшим, күрәм, гомернең
Ерак түгел инде кыясы.
Ярсу аттай чабам, нәфес тели —
Тормыш тәмен күбрәк тоясы.

Килер бер таң иң соңгысы булып,
Чик куелыр типкән йөрәккә.
Сайрар кошлар сагыш моңы бирер
Безнең өстә үскән тирәктә.

Һәр көн туса җиргә су сибәмен,
Дым калсын дип үсәр тирәккә.
Һәр изгелек бүген кешелектә
Саулык өсти кебек йөрәккә.

* * *

Һәркемнең дә үз үлчәве була:
Явызларны таный явызлар,
Изгелекне гаеп итеп сөйли
Кайчагында мәмәй авызлар.
Танымыйлар изгелекне һич тә,
Миһербанлык хисен таптыйлар.
Ләкин күпчелеге бит җирдә, дуслар,
Иманнарын йөртә, саклыйлар.
Ә мин үзем саклыйм иманымны,
Хәер өстим үткән буынга.
Үссен диям җирдә изге булып,
Туучылар безнең урынга.
Сөеп яшим туган балчыгымны,
Горурланам нәсел-ырудан.
Мактанасым килә дөнья ярып,
Әти-әни татар булудан.
Табигатьнең гүзәллеген күрәм,
Тирәнлеген тоям диңгезнең.
Диңгез сулары да юа алмый
Изгелеген туган нигезнең.
Саулыгыма куанам да кайчак,
Шөкер итәм Аллам каршында.
Яшәвем дә — изгелекләр эзләү,
Иманымны туплыйм башымда.
Туган телем белән горурланган,
Назлар искән чакта уңайга,
Илһамланып атап дога укыйм
Татар улы бөек Тукайга.

* * *

Кичер мине, әгәр күңеленә
Яра ясап китсәм ялгышып.
Син белмисең, миңа да бит мәңге
Калмый йөри ул тәм ябышып.

Шаян яшьлек, шаяргандай гына,
Кочмак булып сузды кулларын.
Син дә, мин дә ләззәт кенә сиздек
Кырын, төбен күрми уйларның.

Күңел тартты, чиксез шатлык сөрде,
Сизми таң аттырдык төннәрне.
Саф, эчкерсез сөйли, көлә идек,
Күзгә терәмичә күзләрне.

Оялгандай идек икебез дә,
Курка идек кыек басарга.
Яшь идек шул, белмәгәнбез
Кирәклеген серләр ачарга.

Ул тойгылар тарих булып калды,
Бутадылар безне язмышлар.
Яшьлек тәмен күмә, таплый алмый
Язмыш сүзен кушкан ялгышлар.

* * *

Белмим, нигә кочаклады берәү
Яшьлегемдә кочып билемнән.
Хәтерләмим, үбә белдемме икән
Шул «юләр»нең алсу иреннәннән.

Гаеп түгел, яшьлек хыяллары
Алар бездән бик тиз үттеләр.
Уналтыны тутыруга инде,
Сугышка дип солдат иттеләр.

Мари урманнары солдатларны
Шешендергән чакта ачлыктан,
Минем барча булган сөякләрем
Шалтыраган иде ябыклыктан.

Һава десантлары ул заманда
Бик янәшә иде үлемгә.
Без, исәннәр, бүген яшәү белән
Бурычлыбыз сабыр-түземгә.

Десант. Сержант, офицер булдым
Хәрби булып үткән юлымда.
Эчке моңым белән сүзен тездем
Музыкасыз туган җырымда.

Ә кыйблам авыл минем һаман,
Чабаталар күптән тузса да.
Сагындыра, каһәр, моңы, зары белән,
Яшьлек үкенечле узса да.

* * *

Мәхәббәт җырларын элек
Җырлый идем яратып.
Хатынымны тота идем
Күзләремә каратып.

Күңел төште, җырым сүнде,
Корый бугай гөлләрем.
Хатын белән сугышмасам,
Үтмәс кебек көннәрем.

Мин сүгенсәм, ул чәбәкли
Ошамаган җирләрен.
Ул ясаса яра башка,
Мин күгәртәм күзләрен.

Дөбер-шатыр көн итәбез,
Бик ныклы безнең нәсел.
Ничек кенә яшәсәк тә,
Яшәсәк иде тигез.

* * *

Беркөн төштә саташканмын, каһәр,
Бик борчылып, елап уяндым.
Имеш, хатын «иркәсенә» дигән
Айлык талонымны җуйганмын.

Әй ялынам, хатын бар дип белми,
Тап талоның, имеш, булмаган,
Белгәннәр бит, сабынныкы…
Бик кирәкле талон урланган.

Менә, малай, зур борчылу бу,
Эзлим, саклыйм качып ялгызым.
Бурны тотып, файдаланган чакта
Өнен алалам, имеш, явызның.

Аю кадәр адәм әнә талон суза,
Беттем, хатын аңа елмайгач...
Явызланып бурга сикердем дә
Шөкер иттем... кисәк уянгач.

* * *

Гәүдә олы, фикер зурдан,
Тик бар эш тә килми кулдан.
Мин, мин, диеп вакыт узган,
Чыга алмый бик тар юлдан.

Мулла булып кыйлансаң да,
Артистланып оялсаң да,
Соңга таба уйлансаң да,
Искәрмәсләр югалсаң да.

Яшьлегеңдә тәм күп була,
Күбәләкләр чиксез куна.
Өстә киемнәр дә туза,
Сиздермичә гомер уза.

Алда ни киләсен уйла,
Нәфесеңә күп юл куйма.
Кешеләргә хөрмәт җуйма,
Бәхетеңә киртә корма.

Исәрләнеп, артык чапма,
Кор нигезең көчле чакта.
Тиле яшьлек калгач артта,
Мәгънәсез калма чатта.

* * *

Картка санаган буламы,
Карчык ачмый кочагын.
Сиксәнем дә тулмаган бит,
Нинди карт ди, пычагым!

Кирәк-яракка базарга
Мин чабам бит хәзергә.
Мунча ягам, чәен куям,
Аны уятам әзергә.

Ирләр бар да яраталар
Хатын-кызның куштанын.
Карчык шуны төшенмәсә,
Юмам әле ыштанын...

## *Җирдән китмә*

Син биргән тәмле минутлар
Атка менгезде мине.
Канатлы ат алга чаба,
Күрәсе килеп сине.

Айга менеп, йолдызлардан
Шул мизгелләрне эзлим.
Хис, хыялда күзем йомып,
Гүзәлем, сине күзлим.

Җирдән китмә, мин дә җирдә,
Күңелем генә күктә.
Тәм бирер гүзәл мизгелне,
Юк, бушка әрәм итмә.

## *Язмышым куша*

Юк, теләмим, һич күзләмим
Очраклы үбәргә.
Язмыш миңа язган инде
Ялгыз яшәп түзәргә.

Мин теләгән, күзләгәннәр
Очтылар ерак күккә.
Юк, орышмыйм, рәнҗемим,
Язмышта минем үпкә.

Теләгәндә, үрелгәндә,
Суктылар арттан тезгә.
Югалды мин үрелгәннәр
Күренмиенчә күзгә.

Йөрәк ярасы төзәлми,
Канатым сынды шунда.
Яшәргә язмышым куша
Чумып сагышка, моңга.

## *Адашканнар турында*

Бозык ана үз сабыен
Ташлап китсә урамга,
Бу — исбатлау очрауны
Кешелек җил-буранга.

Адашканнар җил-давылда
Табалмасалар өйне,
Арса, өшесә кешеләр,
Нәрсә көтәсең инде?

Кортласа, агач та чери,
Үтерә китмәс чирләр.
Чыланмасынга аяклар,
Бармы икән коры җирләр?

И бер Аллам, акыл бир син

Сатып алмаска чирне.
Акчалы чирдән коткарыйк
Гүзәл, чәчәкле илне.

* * *

Керәшендә минем туганнар бар,
Аралашам, хөрмәт күңелдә.
Очрашып, ул тәртенгән чакта,
Иманымны укыйм үзем дә.

Яшәгәндә һәрчакта да көлеп,
Бәйрәм итеп кенә йөрмисең.
Якыннарга хөрмәт чын, саф булса,
Кимчелекләрен дә күрмисең.

Әгәр кемдер гайбәт сөйли икән,
Бармак төртеп, кеше сөймичә,
Ышанмагыз андый гайбәтчегә,
Ул — яшәүче яши белмичә.

* * *

Очрашсам, чиксез бәйрәм тоям,
Киләм көткән күңел языма.
Тик аңламыйм, нинди көчләр, әйтче,
Тарта мине синең яныңа.

Бергә чакта канатлана гомер,
Чәчәк ата күңел гөлләрем.
Синең шәүләң күрсәм, исең сизсәм,
Ләззәт белән үтә көннәрем.

Мең-мең яшә, Алла саулык бирсен,
Сиңа изге хисләр күңелдә.
Аермасын ләззәт-назларыңнан,
Көннәр өстә минем гомергә.

## *Солдат дусларга*

Хөрмәт иттем барлык милләт халкын:
Поляк, үзбәк, казакъ, русларны...
Сагынып яшим озын итәкле
Шинель кигән солдат дусларны.

Ачлы-туклы озын юллар үттек,
Җирдән йөрдек шуып, үрмәләп.
Насыйп кылсын иде шул дусларны
Елап сөйләшергә, күргәләп.

Кемнәр кайда, ничек яшәгәндер,
Җавап бирә алмыйм ансына.
Солдат котелогы күз алдымда,
Җылы хисләр яши барсына.

Күрешмәсәк, дуслар, бәхилләшик,
Яхшы фикер саклап күңелдә.
Бүлеп капкан солдат шулпалары
Саклагандыр диям гомергә.

* * *

Сагындыра чебен-черкиләр.
Җиләк җыйдым урман, тау битеннән,
чебен-черкиенә сүгенеп.
Бара алсам, җиләк җыяр идем,
Тагын корты чакса сөенеп.

Вакыт үтә, барын алып китә,
Җиләкләр дә төшә өзелеп.
Күзләр җиткәч, йөрәк хәлең беткәч,
Җиләк җыеп булмый сүгенеп.

Күңел тели, ләкин дөрес күрми,
Онытылып кала таягың.
Җиләкләре күз алдымда яши,
Алып бармый, каһәр, аягым.

Тормыш иткән чакта, бик кадерле
Каз, үрдәге, тавык, чеби дә.
Килә бер көн, сагындыра икән
Сүгендергән чебен, черки дә.

* * *

Җаным тарткан якынымның
Йомшак иде куллары.
Йомшак булса да куллары,
Мәгънәсе булмады.

Аракыдан арынганда,
Тәмлене бик ярата.
Алган айлык хезмәт хакын
Кырык кабат саната.

Кварталга бер мәртәбә
Алып керәм мунчага.
Ике сәгать җебеткәндә,
Бетә ике мунчала.

Хуҗалыктагы эшләрнең
Танымый бер төрен дә.
Мин, мин диеп өстәл суга,
Йоммыенча күзен дә.

Иртүк торып маллар карыйм,
Туйдырамын этемне.
Эшкә киткәнче җитешсәм,
Искә алам иремне.

* * *

Көз килгәнен беләм көннәремә,
Игътибарым артты гөлләремә.
Минут өстәрмен дип гомеремә,
Ләззәт эзлим көчләп күңелемә.

Мөмкин кадәр телим шат көләргә,
Орышынмаска һич тә, түзәргә.
Борчылмаска диеп юк сүзләргә,
Гүзәллекләр табам гел күзләргә.

Күңелемдә исә назлы җилләр,
Борчу бирми кичкән тапсыз җирләр.
Бик күп чәчәм җиргә гүзәл гөлләр,
Гомеремә өстәлсен дип көннәр.

* * *

Керәшеннәрне яратам,
Туры йөрсә юлында.
Ләкин нишләп йөриләрдер
Безнең мәчет янында.

Муенында тәресе бар,
Әлхәм укыган була.
Рус бәйрәме булса,
Чиркәүгә таба шуа.

Чиркәүдә дә, мәчеттә дә
Керәшеннәр гел түрдә.
Кырык төскә керә-керә,
Үзгәрәләр бит көн дә.

* * *

Тыңла, ярат кошлар моңын,
Сизеп яшә җилләр назын.
Искә алмый сөю барын,
Әрәм итмә гомер язын.

Күр син, кара кояш нурын,
Һич онытма сөю барын.
Бел син, җилгә бирмә берүк
Гомереңнең ләззәт-назын.

Тыңла, йөрмә күккә карап,
Синдәйләргә үсми канат.
Сөй син, сөел һәм иркәлән,
Аңла: гомер килми кабат.

Җирдә тудың, шунда урының,
Күп буталды безнең буын.
Ач күзеңне, аңлап барсын:
Җирдә калсын сүнмәс җырың.

## *Ә безнеке эчми-тартмый, ләкин артмый...*

Ут очыра күрше, майга чумган,
Утта янмый, суда батмый ул.
Ә безнеке тырыш, янып эшли,
Эчми, тартмый, ләкин артмый ул.

Күрше эчә, җырлап-биеп яши,

Эт асрый олы танадай.
Ә безнеке башын, билен игән,
Песи сөя сабый баладай.

Ят кешеләр күрсә, күрше каушый,
Көлгән була, дер-дер килсә дә.
Ә безнеке бер дә чапаланмый,
Коралланган гаскәр күрсә дә.

Иншалла, аек баштан йөреп,
Өйрәнмиенчә дә тартырга,
Эштән бөкересен чыгарып та,
Язмагандыр артырга.

Өмет олы: еллар юл яргандай
Билен игән хезмәт халкына.
Көтәм әле, керем артыр, бәлки,
Этен саткан күрше хакына.

## *Мескен*

Күрдем өреп кабарткандай
Дуңгыз сыман бәндәне.
Бик аптырап карап тордым
Сырлы, бозык гәүдәне.

Бүксә үскән, бот җәелгән,
Борылмый, бөгелми дә.
Эшкә, ашка, башкага да
Сүнгән ул, үрелми дә.

Туганда, кеше булган ул,
Үскәндә, үскән уйнап.
Каен төбенә юл алган,
Эшсез яшәргә уйлап.

Табигать ул гадел, дөрес,
Тик үзенчә яшәтә.
Килгәч яшәсен иде диеп,
Кешеләрне эшләтә.

## *Ачык хат*

Дога тапмагандай үз җиреңдә,
Бәхетеңне күктән эзлисең.
Сине үстергән әти-әниеңнең,
Башкаларның көчен күрмисең.

Сый-хөрмәтнең чиксез муллыгында
Өстәлеңне нигә буядың?
Бик кечкенә маймыч була торып,
Зур балык мин диеп уйладың.

Һәр шофер да, әгәр беләм диеп,
Самолетта очмак булганда,
Белеп яши камил акыллылар,
Күктә әзер асфальт юк анда.

Менгән чакта кирәк карау, белү
Баскычыңның булган сырларын.
Белмәү начар олы бу дөньяның
Сиңа язган такыр кырларын.

Колхоз фермасында, башка җирдә
Белмәгәннәр бик тиз буяла.
Син буялган дөнья шакшылары
Күпләр өчен сәбәп уйларга.

Үзе мулла, үзе тырт иткән дип,
Зур гыйбрәт сөйли кешеләр.
Халык сүзен искә алмый яши
Тәрбиясез сезнең ишеләр.

Кешеләргә хезмәт итәм диеп,
Эш хакы алдың, йөрдең хөрмәттә.
«Волга» белән чаптың, ләззәт таптың
Өч тиенлек эзсез хезмәттә.

Почмак саен зарланасың менә,
Сасыттың да яшәр һаваны.
Эзләп тапкан малай сыйфатында
Кунак итмәсеннәр анаңны.

Акыл җитмәсә дә, яшең бар бит,
Өйрән кайдан нәрсә киләсен.
Кешеләрне ярат, бел син җирнең
Нәрсә чәчсәң, шуны бирәсен.

* * *

Чыр-чу килгән бала-чага сыман,
Сикергәләп ага кар суы.
Язмышлары, ялгышлары белән
Һәр тамчының була үз юлы.

Тәкъдир микән, карлар, эреп агып,
Зур елгалар ясый нигездә.
Кайберләре тамып җиргә сеңә,
Кайберләре җитә диңгезгә.

Кар сулары сыман, бик челтәрле
Дөньябызда безнең язмышлар.
Диңгезләргә илтми, җиргә тарта
Күбебезне ялгыш, каргышлар.

## *Үткәнне һәм киләчәкне уйлап*

Солдат, нужа шулпаларын
Һич тә оныттырлык түгел.
Кай мизгелләр онытылса да,
Моңнарын саклый күңел.

Еллар бутый солдат язмышларын,
Утлылары каты пешерә.
Ач, ялангач үткән канлы юллар
Төшкә кереп искә төшерә.

Йон чыкмаган сабый,
малай — солдат,—
Үлгәннәрнең киеп киемен,
Ач шешенеп, ком казыган чакта,
Тәмен тоя микән иленең?

Мин хәтерлим мари урманнарын,
Волоколам урман сазларын.
Бар кешелек хыялланып көткән
Җиңү биргән ямьле язларын.

Без ашардай икмәк озак үсте,
Озак тарттык нужа арбасын.
Өмет кенә ялкынланып көтте
Җиңү бирер диеп яңасын.

Күп сөйләнде купшы,
матур сүзләр
Тик санаулы көннәр тиз үтте.
Ышандырган алтын таулар бетте,
Сайлау үткәч, каядыр китте.

Бик аптыраш: байлар бик күбәйде,
Югарыдан бармак яныйлар.
Тырышканнар, әйдә, баесыннар,
Депутатлар шулай байыйлар.

Ач булсам да, солдат елларымда
Ярны күрде өмет күзләрем.
Җитәкчеләре дә, закон танып,
Дөрес сөйли иде сүзләрен.

Ярын күрмим,
яшәү — омтылышсыз,
Сукыр сыман барам юлымда.
Рухи бөеклеген мактап сөйлим
Яшьтәшләрнең сугыш елында.

Авыр еллар. Күп корбаннар алды.
Белеп барды солдат үлемгә.
Җиңүчеләр тиеш хөрмәт алмау
Авыр тойгы бирә күңелгә.

Милләт тамырына балта чапкан
Авырулар илдә күбәйде.
Аралашу, мөгамәлә
Исерткечләр аша көйләнде.

Чагыштырсаң, дөрес, үзгәреш бар,
Тамак туйды, кидек итекләр.
Тынычсызлык җанны каты борчый —
Тимердән бит тәрәз, ишекләр.

Рухи яктан артык йомшардык,
Бердәм табынабыз акчага.
Зур игътибар итик бу тармакка,

Акыл, бәхет үсми бакчада.

Кимчелекләр булмый калмас инде,
Зарланганнан файда табылмас.
Бердәм көрәшмәсәк, тырышмасак,
Тормыш тишекләре ябылмас.

Кимчелекне белеп яшәү кирәк,
Төзәтергә корып планнар.
Кимчелекне кимрәк күрсә иде
Киләчәктә туар оланнар.

## *Гомер көзем*

Гомер көзем, эзләремне барлыйм,
Йөрәгемә алган яраларны саныйм.
Яшьлегемне йоткан ач-ялангач
Гасыр чире — сугышларны каргыйм.

Чебен-черки сыман, кеше үлде,
Сабыйлар да бәхетсезләр иде.
Карт, карчыклар, үзе ашамыйча,
Солдатларга эшләп ипи бирде.

Еллар үтте, чабаталар бетте,
Исән калганнар да кайттылар.
Дөнья тыныч түгел, Алла каһәреме,
Яман чирләр җирдә арттылар.

Исерекләр, төрле авырулар,
Явыз җанлы адәм күбәйде.
Мөгамәлә никтер күп үзгәрде,
Бер-беренә хөрмәт әзәйде.

Рәнҗетү белән чутлашмыйлар,
Игътибар юк хәер-догага.
Законнар бит кәгазь битләрендә,
Гаделсезләр хуҗа дөньяга.

Табигатьтә язлар кабатлана,
Кешелеккә язлар килерме?
Кара болытлардан бер арынып,
Аяз, кояшлы көн күрерме?

## *Тирән эзләр*

Күңел әрнеп, йөрәк сызланганда,
Бозланганда барыр юлларым,
Күзләремә яшьләр тулып җырлыйм
Солдат елларымның җырларын.

Тимер юлның товар вагонында,
Солдат шинеленә төренеп,
Тәгәрмәчләр моңын күп тыңладым,
Чиксез, кырсыз күккә үрелеп.

Аерганда якын туганнардан
Аңсыз, җансыз калган гәүдәмне,

Поезд, машиналар күп йөрттеләр
Борчылулар тулган шәүләмне.

Волоколам урман сазлыгында
Күпер ясап тигез урында,
Тәре куйган күп каберләр калды
Солдат булып үткән юлымда.

Җан әрнеткеч сызлау, сыкрау булып
Искә төшә үткән юлларым.
Гүзәл мизгелләрне тапландыра
Тирән эзле солдат елларым.

* * *

Килер бер көн, тәнем генә түгел,
Йөрәк җылысы да сүрелер.
Ләкин, үз чамасын дөрес белми,
Күңел сиңа таба үрелер.

Һәр көн безгә бәйрәм бирсен иде,
Кадерләргә күңел язларын.
Искә алу үзе яшәү бирә
Бер-береңнең иркә назларын.

Мәшәкатьле, бик катлаулы дөнья
Оныттыра назны, тәмнәрне.
Хезмәтеңә кушсаң мәхәббәтне,
Савыктыра күңел, тәннәрне.

Рухланып эшли, яши алсаң,
Алла гомер өстәр көннәргә.
Мәхәббәттә янып, очып йөрсәң,
Су сипкәндәй була гөлләргә.

* * *

Булган изгелекләремә
Биргәнеңне юрадым.
Көн-төн яуган яңгырыңа
Йөрәгемнән еладым.

Рәхмәтле, әй бер Аллам,
Уң кылдың елларыңны.
Кырга бирдең, кулга да бир,
Хур итмә колларыңны!

Аллам! Ваемсыз булмабыз,
Аңлап ни диярләрен.
Гафу ит, кичер җәзаңнан
Без гөнаһ ияләрен.

Әй Раббым, булганыңа
Мең-мең шөкер, Ходаем,
Биргәнеңне алма инде,
Зинһар, бир уңаен.

* * *

Яшь чагында яшел була
Болыннарда үләннәр.
Яшел үлән дә саргаер,
Күренсә без күргәннәр.

Тәмле була җиләк-җимеш,
Вакытында пешкәндә.
Өзелеп төшкәндәй тоямын,
Исләремә төшкәндә.

Сары сандугач сайрагач,
Саргая димә гөлне.
Гөлләр саргайгандай була
Сагышта йөргән көнне.

Сагыш бирмә,
бир син ләззәт,
Тынычлык бир күңелгә.
Язгы яшеллекне тоеп
Яшим әле гомергә.

* * *

Соңгы җырым, йөрәк җылым сезгә
Сүнә барган күңел түреннән.
Бу җырларым сезне алып барсын
Без кичергән гомер эзеннән.

Күрегез сез тирән упкыннарны,
Текә ярлар буйлап үтегез.
Биек баскычлардан бу җырларны
Без теләгән чорга илтегез.

Эзләмәгез тигез, шома юллар,
Куркытмасын сазлы үрләре.
Күз алдыңа килсен кырыс еллар —
Безнең буын үткән-күргәне.

Сезгә теләк — насыйп булсын үтү
Тигез, якты, туры юллардан.
Мөмкинлекләр бирсен сезгә безне
Калдырмаска хәер-догадан.

* * *

Әче җилләр ялмап искәндә дә,
Туңдырмаска була барын да.
Тик мин генә куенымда йөртәм,
Саклыйм сине йөрәк янымда.

Шатлык балкый!
Йөрәк эшләп армый,
Күңел канатлана очарга.
Тик ярата белгән кеше генә
Сәләтле ул сөеп кочарга.

Яратыгыз, ярат матурлыкны,

Сөенегез, сөя белсәгез.
Мең яшәрсез, дөнья гүзәллеген
Ләззәтләнә белеп күрсәгез.

* * *

Очрашсам, тулы назга чумам,
Чәчәк ата күңел гөлләрем.
Тик син генә ләззәт чыганагым,
Шатлык биргән аяз көннәрем.

Тайпылмачы туры юлларыңнан,
Сайрар кошын тыңла язларның.
Син онытма: мин бит сине көтәм,
Ләззәтен бир миңа назларның.

* * *

Мин дә явыз, ләкин телем белән
Дару итеп бирәм агуны.
Кулым белән түгел, телем белән
Кирәк саныйм
Дөреслекне ярып салуны.
Кулы белән көч күрсәткән бәндә
Хәтерләтә кыргый кешене.
Сирәк кенә ләкин очратабыз
Бик акылсыз,
Явызлыкта хайван ишене.
Ошамады һич тә иптәшләрен
Кыйнап йөргән явыз малайлар.
Картайгач та чиксез нәфрәт бирә
Тәрбиясез,
Хатын кыйный торган «самайлар».

* * *

Нинди көчләр миңа канат бирә
Текә кыяларга очарга?
Каян килә кайнар, сулмас теләк
Иркәләргә, назлап кочарга?
Яланаяк, тирән кар дип тормыйм,
Үрләр үтәм, ерам сазларны.
Сабырлыгым җуеп, ләззәт тоеп
Каршы алам назлы язларны.
Юк киртәләр үтәр юлларымда,
Юк андыйлар каршы килердәй.
Гел син генә минем уйларымда,
Газап аша тәмнәр бирердәй.

* * *

Гүзәллекнең чиген белми күңел,
Бәйрәм хисләренә табына.
Атка менеп, күккә очар сыман,
Ләззәт таба дуслар янында.

Бик сәләтле шәхесләргә бик бай,
Бик күп биргән талант иясен.

Туганнарча, керәшен дусларыма
Килә бүген башым иясем.

Изге тойгы, тугандашлык бөрки
Һәр адымда бәйрәм һавасын.
Хезмәткә дәрт, алга яшәр өчен
Дуслык бирә тәнгә дәвасын.

Бергә яшәп, без туганлык хисен
Ныгытабыз тырыш хезмәттә.
Керәшене, мөселманы бергә
Аралаштык олы хөрмәттә.

Назыйм, Мәрьям, Асылбикә ханым,
Иван, Начтый, Марҗый, Палыйлар.
Сыер сава, ат җигәләр алар,
Сарык, бозау, дуңгыз карыйлар.

Икмәк басуларын иңләп йөри
Комбайнчы Микай кодабыз.
Ул үзенчә, мин үземчә кайчак
Киткәннәргә дога кылабыз.

Мин бит — мәчет карты.
Алда — өмет,
Тынгы бирми үткән, узганнар.
Чын йөрәктән Питрау көне белән
Тәбрик итәм Сезне, туганнар.

* * *

Сабан тургайлары сайрый
Язын гөлләр куенында.
Карт күңелләр дә яшәрә
Безнең Сабан туенда.

Сабан тургайлары сайрый
Талда инеш буенда.
Сабан туе ләззәтләре
Җитсен гомер буена.

Сабан тургайлары сайрый,
Мактап Сабан туйларын.
Җилкендереп күңелләрнең
Фикерләрен, уйларын.

* * *

Җир астыннан йөргән еланнар бар,
Аларны да белә, күрәләр.
Халык сукыр диеп уйлый бирә
Әле һаман кайбер түрәләр.

Күршесенең өстендәге чүпне
Зур гаепкә санап көләләр.
Ә үзләре тирән кара сазда
Муенгача батып йөзәләр.

Акча, власть бозган вөҗданыннан
Эзләп карыйк исән алмасын.
Инде орлыгы да бозык булса,
Ут төрт, янсын, чүпләр калмасын.

* * *

Их, Мамадыш, Мамадыш,
Һәр ягыңда яңарыш.
Гүзәллегеңә табынам,
Сагыш бирмә син, язмыш.

## *Тик ул гына*

Яннарыннан китеп,
Ялгыз йөргән чакта,
Бигрәк якын булып тоела.
Беркемне дә күрмим,
Йөргән юлны сизмим,
Тик ул гына кала уемда.

Күз алдымда йөртәм,
Күңел җылым итәм,
Сагыш сызландыра күңелне.
Тәннәрең җылысы,
Күзләреңнең нуры
Озынайта яшәр гомерне.

Сагыш бирмә, Аллам,
Читкә илтмә ялан,
Бергә үтсен гомер көзләрем.
Китсәм сагынам,
Сиңа табынам,
Исән, күргән чакта күзләрем.

## *Мин дә үпкәләдем*

Иртә киләм, конфет бирәм
Күп итеп, дигән булды.
Тел сөяксез, яннан киткәч,
Вәгъдәләр онытылды.

Өмет иттем, таңны көттем,
Көн үткәрдем ач килеш.
Телефонын өзеп куйды:
Борчымасыннар, имеш.

Үтте төннәр, әрәм көннәр,
Яраланды күңелем.
Ялганлавы төшендерде
Үземнеке түгелен.

Кабат күрештек, сөйләштек,
Күзгә керә акланып.
Үпкәләдем, дигән була,
Телен чәйнәп, якланып.

Дару түгел, агу салды
Борчылган йөрәгемә.
Мин дә үпкәләдем әле
Ялганчы сөйгәнемә.

## *Онытмыйк*

Күңел тирән һәм бик нечкә,
Тиз бөгелә җилләргә.
Кимсенсә урын табалмый
Һәм бирелә чирләргә.

Мәхәббәттә канатлана,
Оча, чаба күкләргә.
Сөю, назлар дару була
Яшәгәндә күпләргә.

Бер сүз җитә кешеләрнең
Борчырга күңелләрен.
Яра ясап йөрәкләргә,
Кыскарта гомерләрен.

Яра ясамыйк кешегә,
Дару булсын сүзебез.
Матур мөгамәлә булса,
Шатланырбыз үзебез.

Шатлык, канатланып яшәү
Гомер өсти һәркемгә.
Онытмыйк: сөю, сөелү
Артык түгел беркемгә.

## *Һәр гомернең була көзләре*

Еллар белән бергә гомер үтте,
Кыска килде яшьлек язлары.
Авыр тормыш кысты, кыскарттылар,
Картлык инде йотты назларны.

Күңел шаулы. Тау күчермәк була,
Тик йомшак инде буыннар.
Әле мин диеп үрелмәкче булсаң,
Юк, теләми кирәк урыннар.

Чәчәкле яз гүзәллеге үтте,
Ә көзләрнең шиңде гөлләре.
Яфраклары сүнеп җиргә оча,
Санаулы шул инде көннәре.

Гомер көзе нәкъ табигать сыман,
Яфраклар оча җилләргә.
Болытлы һәм салкын тоелалар
Кояшлы аяз, матур көннәр дә.

Юк, көлмәгез шиңгән гөлләр күреп,
Көзләр корыталар гөлләрне.
Һич онытмыйк: көтеп йөрү кирәк,
Һәр гомернең була көзләре.

* * *

Очар чакта оч син биекләргә,
Ерак китми туган төбәктән.
Очар чак дип азып-тузып китеп

Өзелмәсен тамыр үзәктән.

Гомер кыска. Үтә сиздермичә,
Бәя бирми йөрер юлларга.
Каурыйлар коелалар бик тиз,
Таяк килә сөяк кулларга.

Туган якта канат көчле була,
Тәмле була илдә аш-сулар.
Үз илендә тыныч картлык күрсә,
Иң бәхетле кеше ул — шулар.

## *Күбәләк булма*

Мин матур дип бик сикермә,
Матур төсләр кирәк базарда.
Рухи матурлыклар эзләп кара,
Товар булып калма сатарга.

Тыйнак бул син һәр көн бу дөньяда,
Бушап китеп йөрмә сарылып.
Әдәпсезләр, артык «мин» дигәннәр
Басып кала кырда сузылып.

Тышкы матурлыкка эчкесен тап,
Гүзәллегең булсын түгәрәк.
Бәхетеңне сакла, була күрмә
Гөлдән гөлгә кунар күбәләк.

* * *

Мамадышлылар сезне сәламлиләр,
Сәлам сезгә, сәлам, уңганнар.
Кабул итегез сез изге теләкләрне
Бүген монда залда булганнар.

70 еллык истәлекле көнне
Искә алыйк бөтен үткәнне.
Бик кечкенә чишмә — нефтебаза
Олы елга булып үткәнне.

Коллективның үткән тарихында
Бик күп макталырдай эшләре.
Безнең сафта дядя Вася
40 елдан артык эшләде.

Бүген дә бит безнең белән эшли
Уңган, аңлы, тырыш кешеләр.
Рәшидә, Надя, Рөстәмнәр —
Бар да «дядя Вася» ишеләр.

* * *

Шаулап муллык үсү,
Назлы җилләр исү…
Сокланырдай бүген чынбарлык.
Чыклы, назлы таңны,
Матур килгән язны
Елъязмага данлап язарлык.

Кинәт киткән карлар,
Чәчәк аткан язлар…
Табигатьтә — көчнең күләме.
Калкып чыкты йортлар,
Яшәү дәрте — утлар…
Горурланмый күңел түзәрме?!

Кул селтәгән җирләр...
Әрәм сыман тирләр...
Кинәнәбез бүген бодайга.
Мул уңышлар алдык,
Барын җайга салдык,
Үзгәрәбез төптән уңайга.

Өстәлләрдә байлык,
Күңелләрдә шатлык…
Үзгәрешләр ача йөзләрне.
Болар бар да алда
Күмелерләр данга —
Сезнең армас хезмәт эзләре.

## *Фатих Сәүбәновичка*

Без яшәгән чорның елъязмасын
Карар алда туар кешеләр.
Күп булырмы
Тирән эзләр анда —
Калдырганнар Сезнең ишеләр?!

Мин бәхетле бүген — тәбриклимен
Зур хөрмәткә лаек иясен.
Хезмәтенә лаек хөрмәт диеп,
Алтынын да килә күрәсем.

Сез лаеклы олы хөрмәт-данга,
Якташларым аңлый барсын да.
Бу соңгысы түгел, зуры—алда,
Мин ышанам: булыр ансы да.

Күңел тулы зур ихтирам белән
Сокланамын сезнең хезмәткә.
Гаделлекнең бөеклеге шунда:
Зур хезмәткә тиеш хөрмәт тә.

Кемнәр генә ничек хезмәт салмый
Матур яшәү өчен тормышка.
Бөек сәләт меңләгәннәр көчен
Илтә шулай данлы уңышка.

Менә шуңа үз итәбез Сезне,
Чиксез хөрмәт Сезгә халыкта.
Яңгырасын сүнмәс дан җырлары,
Өстәп ныклык Сезнең саулыкка.

## *Туган авылым*

Туган-үскән авылым Тукаем,

Орлык, тамырың синең Кырлайда.
Гүзәллегең ничек чагылдырыйм
Йөрәгемнән чыккан җырларда?

Син шыткансың, гүзәл туган авыл,
Даны чыккан изге җирләрдә.
Гөлбакчадай тамыр җәеп үстең
Бирешмичә давыл, җилләргә.

Авыл уртасында көзгедәй күл —
Нур өстенә биргән нур бит ул.
Һәр куагың күреп яратулар —
Күңел түрендәге җыр бит ул.

Яшә, авыл, изгелекләр бөркеп,
Гүзәллегең саклап гомергә.
Килер буын синдә бәхет тапсын,
Яшәү көче биреп күңелгә.

## *Пычратма намус, исемне*

Гомер юлы гел чәчәкле булмый,
Сырлан, тигәнәкләр үсәләр.
Ә кайчакта күзне ачырмастай
Каршы буран, җилләр исәләр.

Канәгать бул килгән бәхетеңә,
Бик мактанма табып олысын.
Коча күрмә артык төчеләнеп,
Дус түгелдер синең һәр «дусың».

Сөю, сөелүләр —
Алла биргән бүләк,
Горурлан син, сөя белгәндә.
Төчеләнмә, кешелегең сакла,
Бик ышанма сөям дигәнгә.

Ялтыраган бар да алтын түгел,
Саклый күр син татлы хисеңне.
Ояла бел, артык сикергәләү
Пычрата намус, исемне.

Нинди рәхәт янып сөеп яшәү,
Үлчәвеңдә барлап кирәген.
Комсызланып кеше көлдермә син,
Бәяли бел үзеңә тигәнен.

## *Чиген бутама*

Кайберәүләр хәзер курыкмыйлар
Сикерергә янган учакка.
Һич яшерми, тартынмыйча сөйли
Тансыклавын җылы кочакка.

Кешеләргә Алла акыл биргән,
Акыл белән чиклик теләкне.
Йозагында саклыйк, намус таплап,

Бик тәртипсез типкән йөрәкне.

Тарту көче — ике җенестә дә
Җан иясен саклау билгесе.
Бу көчләрне белеп файдалану —
Кешелекнең яшәү көзгесе.

Кеше белән җәнлек аермасын
Акыл саклый, чиген бутамый.
Күңел хисләреңдә чүп үстермә,
Аңлап җиткермичә утамый.

## *Син бәхил бул*

Фәйзетдинем минем, гомер гөлем,
Иртә корып, иртә югалдың.
Белсен дөньям: синнән башка мин дә
Рухи яктан сүндем, югалдым.

Бергә булган ямьле, матур көннәр
Ул — бизәге минем гомернең.
Күз алдымда калган янган гәүдәң
Ярасы шул йөрәк, күңелнең.

Яшем ага, сызлап йөрәк яна,
Уйлап баксам бергә көннәрне.
Сулар сибәм, үстерәсем килеп,
Кабереӊ өстендәге гөлләрне.

Син бәхил бул, дустым, рәнҗемә,
Эзләреңне саклыйм дөньяда.
Бергә чакны эзлим, оҗмах телим,
Мин мәңгегә хәер-догада.

## *Ялган муллаларга нәфрәт*

Күргәнем бар дини фанатикны,
Атеистлар җирдә җитәрлек.
Дини, гыйльми белемлеләр яши —
Тыйнаклыгы исең китәрлек.

Дингә олы, кире күренешне
Күп китерә ялган муллалар.
Аңлы фикер белән белеп яшә,
Бүген күбәйделәр бит алар.

Әлхәм белән Колхуалла ятлап,
Вәгазь сөйли бик күп урында.
Госел, тәһарәтне белмәсә дә,
Мин дип йөргән була урамда.

Мөселманнар теле, көче белән
Зыян китермиләр кешегә.
Кулың селтә, ихлас булмасалар,
Артык «мин» дип йөргән ишегә.

Ихлас белән мин ышанып яшим,

Бер Аллама иман китереп.
Мөмкин булса мәңге яшәр идем,
Ялган, явызлыкны бетереп.

## *Туган илем*

Атам йорты, туган-үскән авыл,
Иркен болын, урман, кырлар, күл,
Чишмә, инешләре, җиләк-җимешләре —
Барысы бергә туган илем ул.

Иркен сулар һавам, балыклы күл,
Үләнендә маллар көткән җирем.
Вак инештән үскән елга, буаларың —
Болары да минем туган илем.

Күңелемә якын туган-үскән ил бар,
Сагыш борчый, китсәм күченеп.
Әйләнәм дә кайтам, яшьләр тулып,
Синнән киткәнемә үкенеп.

## *Алтын бирер идем*

Ирләр исемлеген кулга алып,
Исememне эзләп карадым.
Табалмадым һәм үземнең инде
Картайганлыгымны аңладым.

Әле кайчан гына минем исем
Барысының торды башында.
Каян белгәннәр соң, каһәр суккан,
Чебен төшкәнлеген ашыма.

Күңел һаман мин, мин дигән була,
Сиздермәскә теләп чамасын.
Алтын бирер идем, исемлеккә
Керттерергә тапсам чарасын.

## *Ашыктырма, зинһар*

Сандугачлы чагы үтте инде,
Карга кунды хәзер күңелгә.
Җәйге чәчәкләре шиңделәр дә,
Сары көзе килде гомергә.

Гомер көзе килеп һәркемгә дә
Төрле төсен бирә картлыкның.
Озын язлы көзләр, рухи саулык
Нигезе бит безнең шатлыкның.

Нәфес көчле, бик яшисе килә,
Яктылыгын күреп дөньяның.
Тик, олайгач, чынлап төшенәсең
Мәгънәсен хәер-доганың.

И бер Аллам, шөкер биргәнеңә,
Мин канәгать әле йөргәнемә.
Күп рәхмәт бездәй бәндәләрнең
Кыек эшләренә түзгәнеңә.

Тәүбәм булсын, зинһар, гөнаһыма,
Барсына да түгел, кайберенә.
Хәерле итеп гомеремне сакла,
Ашыктырма зиндан-каберемә.

* * *

Яратам мин барлык кешеләрне,
Хатын-кызга тарта күңелем.
Тартылса да, чапмыйм көләрләр дип,
Аңлап үземнеке түгелен.

Табигый хәл, мондый тартылулар —
Кешелекнең яшәү нигезе.
Кырыс үлчәү белән яшәү кирәк,
Нәфеснең бит төпсез диңгезе.

## *Фәрит*

Сиңа лаек матур сүзләр эзлим,
Олы хөрмәт саклап йөрәктә.
Ныклы саулык, озын, тигез гомер,
Зур бәхетле көннәр теләктә.

Туган көнең белән тәбрик итәм,
Омтылышлар берүк сүнмәсен.
Гомер көзең эзле, озын булсын,
Тәнең картлык сүзен сизмәсен.

Синең яшең — акыл җыйган мәлең,
Ул — яшьлеге алгы гомернең.
Мәңге яшәр изге теләкләрем —
Язын сакла, дустым, күңелнең.

## *Фәридә язмышы*

Пары бетсә, кайбер очар кошлар
Яши алмыйлар бит ялгызы.
Янып сөйгән кешең ташлап китсә,
Бу — язмышның инде авыры, явызы.

Күгәрчендәй гөрләп яшәгәндә,
Салкын гүргә керсә сөйгәнең,
Йөрәгеңә кайнар яра сала
Без — бәхетле парлар дигәнең.

Нәрсә бирә матур гүзәллегең,
Канатсыз кош булып калганда.
Малның тәме, яшәү яме бетә,
Син эчеңнән дөрләп янганда.

Дөрес, Алла матур төс-бит бирде,
Җиңел сөяк итеп тудырды.
Тик, бәхетне бик аз итеп биреп,
Гомереңне иртә куырды.

Күзең килә, якынлаша картлык,
Шатлык биреп, бәлки, елатыр.
Оныттырып барын, көтмәгәндә
Олы бәхет биреп юатыр.

## *Язлар китмәсен*

Китәселәр китте, күчәселәр күчте,
Батыр песнәк калды кышларга.
Яратамын гүзәл табигатьне,
Бик сокланып яшим кошларга.

Язгы кошлар өчен оя ясыйм,
Күзлим каргаларны талларда.
Илен сагынып кайткан
барлык кошлар
Җан өстиләр безнең язларга.

Чәчәкле яз, сайрар кошлар моңы
Дер селкетә күңел кылларын.
Гүзәллекләр, сөю дәрте биреп,
Тудыралар йөрәк җырларын.

Көзләрне дә алтын диләр, ләкин
Гомер көзе ашыгып килмәсен.
Табигатьне теләп үзгәртмиләр,
Күңелләрдән язлар китмәсен.

## *Кайтам*

Кайтам, бәгърем, кайтам яннарыңа,
Сагыш сарды инде күңелем.
Аерым яшәү ныклап төшендерә
Синсез яшәү мөмкин түгелен.

Күңел чәчәкләре тиз коела,
Җан җылыңнан китсәң еракка.
Сагыш борчыганда күңелеңне,
Ямь табылмый җырлап, елап та.

Мин бәхетле сине яратканга,
Сизеп яшәгәнгә син барын.
Син булдың, бар, мәңге булачаксың,
Яшәү биргән бердәнбер парым.

Гомер көзе барын уйландыра,
Югалтудан курка күңелем.
Пар канатлы булып яшәү генә
Озайтадыр кеше гомерен.

И бер Аллам, сәҗдә кылып сорыйм,
Тигезлектән берүк аерма.
Гомер көзләремә чәчәк биргән
Яшәр канатымны каерма.

## *Үзәгендә күңелнең*

Кан саугандай ярсып типте йөрәк,
Ватар сыман күкрәк сөяген.
Үзем түгел, шәүләм генә йөрде,
Ерак калгач якын сөйгәнем.

Яратуның көчен үлчәп булмый,
Көч юк сыман каршы торырлык.
Көч юк кешелектә җәмгыятьне
Аерылмастай итеп корырлык.

Йөрәкләре яна кошларның да,
Югалтсалар очар парларын.
Кешеләр бит аңсыз, җансыз кала,
Җуйса бермәл сөйгән ярларын.

Күп кичердем андый газапларны
Яшьлек елларында гомернең.
Сагышларда йөрткән сөйгән иркәм
Үзәгендә яши күңелнең.

## *Омтылырга кирәк яшәргә*

Бөреләнеп чәчәк аталмаган
Гүзәл гөлгә охшап каласың.
Аңлыйсыңмы атаң, анаңнарның
Утсыз, көлсез эчтән янасын.

Яфраклары иртә коелсалар,
Агачлар да зәгыйфь үсәләр.
Зәгыйфь агач төзелешкә бармый,
Шуңа утын өчен кисәләр.

Кешеләргә Алла акыл биргән,
Аерырга акны карадан.
Акыл, әдәп, тәртип ярдәм итә
Сакланырга бәла-казадан.

Уйламыйча яки җиңел уйлап,
Ялгыш атлап ярдан егылсаң,
Гаепле бит үзең, үзең генә
Яман юлдан китеп югалсаң.

Нык селкенеп кагынырга кирәк,
Табынырга кирәк Аллага.
Омтылырга кирәк яшәү өчен,
Акыл туплап бүген, алда да.

## *Гомер өчен саклыйк йөрәкне*

Ачykканда ипи, сусаганда суның
Тәмен сакла йөрәк түрендә.
Булган мөмкинлекнең ләззәтен тап,
Сүнмәс шатлык тусын күңелдә.

Чикләнмәгән нәфес бутамасын,
Кыскартырга теләп гомерне.
Шиңдермәсен усал җилләр безне,

Горур, канәгать тот үзеңне.

Яшәгәндә, дөрес, бар да кирәк,
Тик мөмкинлек чикли кирәкне.
Мөмкинлекне дөрес бәяләми,
Рәнҗетә күрмик йөрәкне.

* * *

Колак озын, күзләр уйный,
Күп ишетә, күп күрә.
Куянны эштән алдылар
Бик күп белгәнгә күрә.

Атны да эштән алдылар,
Ишәк аның урынында.
Бер сүз әйтү мөмкин түгел,
Хөкем ишәк кулында.

Якын киләм димә аңа,
Бик мулдан бит коралы.
Илгә файда булмаса да,
Шундый хәлләр бар әле.

## *Югалма*

Кагылма син күңел кылларыма,
Хисләремне санап беткәнгә.
Шәүләң дә бит мине алып кайта
Үткәндәге матур көннәргә.

Күп мизгелне йөрәк җылым белән
Саклап йөрим күңел түремдә.
Күз алдыма килсә чәчәкле яз,
Яшәү көче сизәм үземдә.

Язларымны чәчәкләргә күмдең,
Күзләремдә шул яз төсләре.
Күңелемдә тирән тамыр биреп
Син үстергән яшьлек хисләре.

Рәхмәт сиңа үткәндәге өчен,
Яңартырга сәбәп чыгарма.
Тәннәремдә җылы саклау өчен,
Күзләремнән гелгә югалма.

## *Гаделлек кирәк*

Җир астыннан үтү мөмкин түгел,
Таулар киссә барыр юлыңны.
Ай, кояшсыз кала гомер көнең,
Җилләр алса йөрәк җылыңны.

Янып омтылганда алга табан,
Тәгәрмәчкә таяк тыксалар,
Гүзәллекне эзләп үрелгәндә,
Бик авыр шул кулга суксалар.

Теләләсең рухи кыяларга,

Йөрәк кайный, ачу кузгала.
Җиңеп үтәр көчләр күрелмәсә,
Якты дөнья тәме югала.

Кешеләрнең көче тигез түгел,
Күпләр явызлыкка омтыла.
Җирдә туа үлем, фаҗигаләр,
Канга сусап, мылтык атыла.

Барча халык бердәм тупланганда,
Канатландырмабыз явызны.
Сарык түгеллекне аңлыйбыз без,
Чикләү өчен бирән авызны.

Җир янганда, исән калганнар бар,
Көчне туплыйк яшәү хакына.
Таләп итик һәрбер хакимдардан,
Гадел булсын илгә, халкына.

* * *

Яраттым мин тузан ерган,
Шәрә сабый чагымнан.
Шуңа яланаяк йөргән
Урамымны сагынам.

Инешемнең вак балыгы
Тартып тора бүген дә.
Аулак өйләр, тальян моңы
Яши күңел түремдә.

Исән кебек әле һаман
Без чабышкан тайлары.
Йөрәкләрне җилкендерде
Авыл сабан туйлары.

Өзгәләнгән, сихерләнгән
Мәхәббәт ялкыннарын
Мөмкин булса бер мизгелгә
Кабатлар идем тагын.

Күз алларымнан китмәсен
Шул гүзәл үткән эзем;
Миңа бәхет, яшәү биргән
Туган як, туган илем.

## ***Уйла***

Буй-сының да ярарлык,
Йөз-битләрең карарлык.
Синдә олы кимчелек:
Син бит һәрчак исерек.

Кешеләр синнән көлә,
Югала диеп белә.
Дуслар кырын карыйлар,
Булдыксызга саныйлар.

Аек чакта өйләндең,
Тормышыңны көйләдең.
Исереп, хатын кыйныйсың,
Белмим, нәрсә уйлыйсың.

Кыйнап ләззәт алырсың,
Тик хатынсыз калырсың.
Әле алда күрерсең,
Ач-ялангач йөрерсең.

Исерекләр югала,
Гомерең шуңа бара.
Керәм димәсәң утка,
Эчкечелектән тукта.

Яшәү турында уйла,
Хезмәтне читкә куйма.
Кешеләр зурлап йөрер,
Ерактан сәлам бирер.

## *Җырла, татар*

Татар булгач, җырсыз, моңсыз булмый,
Җырла, халкым, җырла, тартынма.
Өмет белән алга таба кара,
Горурланып кара артыңа.

Татар халкы — эшчән, батыр халык,
Санап тоткан гомер сәгатен.
Кайда барса, шунда тамыр җәйгән,
Күрсәткән ул яшәү сәләтен.

Хәрамнарны белгән хәрам диеп,
Хәләл булган тапкан маллары.
Дошманнарга явыз була белгән,
Рухи көчле булган җаннары.

Җырла, татар. Синең җыр-моңнарың
Яңгырасын дөнья күгендә.
Татар җырын, моңын, данын сакла
Хөрмәт белән йөрәк түрендә.

## *Тәрбия турында*

Тәрбияле булса балалар,
Яши гомер буе хөрмәттә.
Дөрес тәрбиянең төп нигезе —
Яшьтән өйрәтү ул хезмәткә.

Тәрбия дип балда, майда тотсаң,
Өйрәтмәсәң акча санарга,
Бала үзе борынын чөеп
Өйрәнә ул күккә карарга.

Яшәү — җирдә.
Җирне сизми йөрсәң,
Син бәхетсез гомер-гомергә.
Егылуны, бәрелүне белми,

Өйрәнмисең атлап йөрергә.

Яшәгәндә, дөрес, бар да кирәк,
Ашау, эчү, матур кием дә.
Сөйләшергә кирәк күп телләрдә,
Иң беренче туган телеңдә.

Хата ясаганда төзәтмәсәк,
Бала күңеле бик тиз бозыла.
Чыбык чакта бөгеп өйрәнмәсәк,
Таяк булгач, инде соң була.

* * *

Наркоманнар, эчкечеләр
Черетәләр милләтнең нигезен.
Хезмәт сөйми, исереп,
Бозалар татарның исемен.

Үлә ирләр, хатыннар,
Ирләр күбрәк кырыла.
Акылсызлык һәм көчсезлек
Гомерне бик тиз куыра.

Ир-егетләр азайды,
Парга оча, җирдә эриләр.
Ахмаклыктан күбесе
Яшәү тәмен, ахры, белмиләр.

Кадерен белик гомернең,
Без болай да кунак дөньяда.
Акыл тупла хезмәткә,
Өметләнеп хәер-догага.

## *Эзләр турында*

Күккә карыйм, йолдызларны саныйм,
Җиргә сәҗдә кылып табынам.
Гомеремдә эзләр күп ясадым,
Яшьлек эзләремне сагынам.

Гомер көзем күргән мизгелләрне
Барлап йөрим күңел төбеннән.
Сайлап кына алып булмас инде,
Киткән чакта дөнья йөзеннән.

Горурланыр чаклар аз булмаган,
Юк түгел шул кыек эзләр дә.
Үкенечләр артта күп калганнар,
Менелмәгән кирәк үрләргә.

Үткәннәрне төзәтергә теләп,
Белгәнемчә укыйм догамны.
Сәләтемне бирәм изге эшкә,
Матурларга теләп дөньямны.

Без бит җирдә бары кунак кына,
Санаулы көн уза тизрәк.
Гомер сәгатьләре кыйммәтләнә
Картайгачтын инде бигрәк.

Һәркемнең дә гомер эзе кала,

Аермасы бик күп эзләрнең.
Сокланырдайларын карап туймыйм,
Кайбереннән кача күзләрем.

Гомер юлы һәркемнеке дә бар,
Бәхет, шатлык белән узсыннар.
Алгы буын искә алсын өчен,
Сокланырдай эзләр калсыннар.

## *Шулай, дуслар*

Йөрәк яралаган ызаннарны
Тигезлисе килә күңелнең.
Яңартуы авыр күп тапталган,
Чәчәкләре шиңгән гомерне.

Сугыш елындагы яраларны
Каешланган итеп кичерәм.
Хакимлеккә менгән шәхесләрнең
Этлекләрен уйлап исерәм.

Заманымның вәхшилеген күреп,
Эзлим нигезләре чынлыгын.
Гаделсезлек, ялган, нахакларда
Эзләп табам аның орлыгын.

Хакимлеккә менү — баер өчен,
Сарык кебек санап халыкны.
Судан түгел, талап кына җыя
Адәм кесәсеннән балыкны.

Баерга дип түгел, уйласа иде
Эшләргә дип, халкы язмышын.
Чын җитәкче булып үсәр иде,
Аңлар иде беркөн ялгышын.

Шулай, дуслар, вәхшилекнең башы
Баерга дип килгән хуҗадан.
Гаделсезләр хөкем йөрткән чакта,
Халык арына алмый нуждан.

## *Без бурычлы*

Без бурычлы пар канатлар биргән,
Безне үстергән туган авылга.
Изге теләкләрем кайнап тора
Аш-су булсын диеп табында.

Җаннарымны ярып бирер идем
Авылдашларымның хакына.
Янып яшим, бәхет, саулык теләп,
Без үскән авылым халкына.

## *Нигә кирәк*

Үзе көлә, үзе сүгә,
Ни акыллы, ни дурак.

Эше дә юк, кирәк аны
Эткә бирергә турап.

Урманда агач очрый,
Бер файдасыз корганнар.
Нигә кирәк дөньябызга
Сан өчен дип туганнар.

Һәрбер туган балаң сиңа
Үзеңнән кадерлерәк.
Бала түгел, бәла булса,
Тумавы хәерлерәк.

## *Акыл белән яшик*

Ап-ак кар өстеннән атлап барам,
Саф һавалы кышка сокланып.
Явыз бураннары уйнаганда,
Ятам юрганыма ышыкланып.

Юк, батырлык түгел, ахмаклык ул
Юлга чыгу көчле буранда.
Яхшы хуҗа, хәтәр-хәвеф сизсә,
Этен чыгармый бит урамга.

Көрәшәбез каршылыклар белән,
Төпле акыл туплап күңелгә.
Көчең җитмәгәнгә каршы барып,
Чик куюың мөмкин гомереңә.

Тирән уйлап, нык сабырлык белән,
Зур тырышлык куеп хезмәткә,
Тормыш бураннарын үтеп була
Бик бәхетле, олы хөрмәттә.

## *Китәм инде*

Таңнарны көтәм,
Юк, ташлап китәм
Соңга калган яшьлек хисемне.
Якын күрсәләр,
Дус дип белсәләр,
Хурламаслар минем исемне.

Серем бирмәдем,
Бәхет эзләдем,
Көчем салып гадел хезмәткә.
Атам, анама,
Шөкер Аллама,
Картлыгыма килгән хөрмәткә.

Чәчләр уңдылар,
Җырлар тындылар,
Гомер көзем — төсем саргайды.
Вакыт үткәнен,
Тәмнәр беткәнен
Табигать шул үзе аңлатты.

Эзем аз түгел,
Шуңа шат күңел
Гомер елларымның юлында.
Исем табылыр,
Искә алыныр
Киләчәккә барган җырымда.

Күпне күрелде,
Инде сүрелде,
Мәхәббәт җырларын җырламам.
Дөрес, ялганын,
Тузга язганын
Борчылулар белән тыңламам.

## *Яшәү бирсен*

Син бит — миңа Алла биргән бүләк,
Бәхет, шатлыкларга төрелгән.
Син — йолдызы минем гомеремнең,
Иң яктысы булып күренгән.

Гомеремдә минем кемдер килеп,
Фәрештәләр белән котыртса,
Сукмасам да, сүгеп куачакмын,
Кеше икәнлегемне онытма.

Чын ярату тугры, гадел була,
Мәхәббәт бит көчле үлемнән.
Сөйгән, сөелгәннәр — бәхетлеләр,
Бәхет табу, димәк, үзеңнән.

Язмышыма Алла сине биреп,
Гомеремне күмде гөлләргә.
Язларымны саклап, озак итеп
Яшәү бирсен алгы көннәргә.

* * *

Син теләгән кешең җавап итеп
Бәйрәм хисе бирсә күңелгә,
Шатлык хисе сизсә,
җан теләгем, дисә,
Син бәхетле кеше гомергә.

Борчылулар була һәркемдә дә,
Күңел капчыклары буш түгел.
Ямь эзләгән чакта, күз яшьләре
Сөйгән кешең өчен хуш түгел.

Назлар бирә тәннәреңә җылы,
Күңелеңә көчне, дәрт, җырны.
Тәм көткәндә хисләр яраланса,
Хәтерләтә чиксез буш кырны.

Чәчәк атар гөлләр эзләп йөрим,

Гөлләр үсми җансыз кырларда.
Илаһи көч эзлим яшәр өчен
Үлмәс җырларымны җырларга.

Тойсам иде синең яннарыңда
Язгы чәчәкләрнең исләрен.
Айга карап күккә очмасам да,
Җимеш табар иде хисләрем.

* * *

Күп бурычларны түләргә
Рус ача авызын.
Бирмәсләр микән бурычын
Безгә Иван явызның?

Патша бурычын түлиләр,
Оныткандай ил халкын.
Бирергә дә уйламыйлар
Онытылган эш хакын.

Хуҗаның эзен үбәбез,
Мактыйбыз күзне йомып.
Хезмәт хакыңны сорасаң,
Торалар авыз ерып.

Чечняны ваттык, җимердек,
Төзәтә бүген халык.
Хуҗа — буржуй, эшләүчегә
Эш хакын булмый алып.

Вату-җимерү — чынбарлык,
Гаепле кеше кайда?
Урлау, талау ил буенча,
Салынган шулай җайга.

Ата бурлар — иң олылар —
Ил байлыгын саталар.
Кесә тулгач, акча белән
Чит илгә озаталар.

Күрәбез без бик күпләрнең
Симергәнен, бүрткәнен,
Дүрт-биш җирдә үскән йортлар
Ил акчасы икәнен.

Эш хакына акча җитми,
Хуҗалар оча күктә.
Нәкъ хуҗалар теләгәнчә
Үзгәрде дөнья күпкә.

Берәүләр ач, икенчеләр
Чумганнар балга, майга.
Нигә кирәк җитәкчеләр,
Илне салмагач җайга?!

* * *

Җәй көнендә урманнарда йөрдек,
Яңа елга чыршы эзләдек.
Бизәп куйган гүзәл яшел чыршы
Бездә яшәгәнен белмәдек.
Җәй көнендә, сабан туен мактап,
Чабып йөрде малай-шалайлар.
Ничек мактасак та, булганы юк
Сабан туйда кышкы бабайлар.
Тышта ак кар. Зур капчыгын тартып,
Кыш бабайлар йөри кышларын.
Яшел чыршы тирәсендә бүген
Бергә бәйрәм итик, дусларым.

* * *

Сандугачны хөрмәтлимен,
Сайраганга таңнарда.
Яшеллеккә башым иям,
Ләззәте өчен җаннарга.

Сусаганда судан затлы
Берни дә юк дөньяда.
Саулык бетсә, дөнья малы
Килми бит ул уйга да.

Хөрмәт белән эндәшсәләр,
Арттыра хәлен тәннең.
Ялган сүз, балга дегет
кушылгандай,
Ала яшәүнең тәмен.

Саулык — иң олы байлык ул,
Саулыкны ныгытыгыз.
Табигатькә һәм кешегә
Начарны онытыгыз.

## *Дустыма*

Гомер кыска, юллар гына озын,
Үткән юлда эзләр күп калган.
Тирән эзне күрми мөмкин түгел,
Юлдан йөрүчегә сез салган.

Ул юллар бит — үзе олы мәктәп,
Яшәү эталоны күпләргә.
Дан җырлыймын бүген сиңа, дустым,
Исемеңне чөеп күкләргә.

Түрә булып түрдә утырмадың,
Чабатаңны түргә элмәдең.
Горур булдың, ләкин кешеләрнең
Кимсенердәй ягын күрмәдең.

Син — чын кеше, мин яратам сине,
Гамәлеңне, туры сүзеңне.
Чагыштырып кайчак кешелегең,
Орышкалап куям үземне.

Алла саулык бирсен, озак яшә,
Күз салгалап алга, үткәнгә.
Насыйп булсын сиңа дан җырларга,
100 яшеңне бәйрәм иткәндә.

Яшьлек елың җиңел түгел иде,
Туры килгәндер дим тыгызга.
100гә җитү авыр кебек булса,
Ризалаш 99га.

## *Үгет*

Нәрсә чәчсәң, шуны урырсың,
Икмәк чәчсәң, тук булырсың.
Тормышыңны яхшы корырсың,
Эшләмәсәң, ач торырсың.

Белем алгач — булды, диярсең,
Тормышыңны күккә чөярсең.
Бәлки, башта юньле киярсең,
Нәтиҗәсен соңрак сизәрсең.

Ялкау булсаң, сиңа рәт булмас,
Борның чөйсәң, дусларың калмас.
Тир түкмәсәң, тормыш бармас,
Тәкъдир сиңа бәхет язмас.

Яратмасаң сабыйларны,
Хөрмәтләми абыйларны,
Юкка-барга тиен санап,
Кешелеккә ярыйлармы?

Өлкәннәрне олыласаң,
Балаларны яшьтән сөйсәң,
Бәхет килер янсаң-көйсәң,
Кешелеккә хезмәт итсәң.

## *Җырлап барам алгы көнемә*

Урамда кыш, чәчәкле яз миндә —
Сайрар кошлар кунган гөлемә.
Сандугачлар җырын тыңлый-тыңлый,
Җырлап барам алгы көнемә.

Туңдыра алмас кышның салкыны,
Кояш нуры тулган йөрәккә.
Тулган айга табан очар өчен,
Канат эзләп табу теләктә.

Алда якты, җылы нурлар көтәм,
Өмет чаткыларым aклансын.
Сандугачлар җыры гомер өсти,
Күңел сандугачым саклансын.

## *Син — җимеше күңелнең*

Сиңа иркә назлар биреп,
Җил булып исәр идем,

Синең йөргән юлларыңда
Гөл булып үсәр идем.

Өметләремне өзмәсәң,
Ничек тә көтәр идем.
Чакырсаң ерак юлларга,
Үрмәләп үтәр идем.

Син — өмете яшәвемнең,
Син — йолдызы күгемнең,
Сандугачлы матур язы,
Син — җимеше күңелнең.

## *Күңелемдә диңгез дулкыннары*

Күңелемдә диңгез дулкынлана,
Кайсы ярга бәрер язмышым?
Хәер-догаң өмет итәм, әнием,
Курыкканым — синең каргышың.

Язмыш тудырамы моңлыларны,
Моңнар төзәтмиме язмышны?
Нинди җилләр каян китерә соң
Бәхетсезлек биргән ялгышны?

Язгы гөлдәй сандугачлы күңел
Сагыш моңы белән уралды.
Сайрап яшәр сыман гомернең
Сандугачы очты, югалды.

Дәрьяларга илтеп салыр идем
Күңелемә кергән сагышны.
Җиңел генә бизи алмам инде
Кара сөрем сеңгән язмышны.

* * *

Яңа ел яңа бәхетләр,
Тынычлык алып килсен.
Һәркемгә дә шатлык, саулык,
Теләгәннәрен бирсен.

Язлары чәчәкле булсын,
Сабыйлар бик күп тусын,
Һәрбер көн кояшлы узсын,
Кырда икмәкләр уңсын.

## *Гадел түгел*

Якташларым, әй, белсәгез иде,
Ничек кенә үтми бу гомер!
Җир йөзендә оҗмах барын күрсәң,
Сыкранмый калмый шул күңел.

Гадел түгел, берәү сусаганда,

Җимеш суы эчсә туйганчы,
Икенчеләр, сусызлыктан инрәп,
Хезмәт салса аңын җуйганчы.

* * *

Гомер юлым бик түмгәкле булды,
Хәтәр дулкыннарда күп йөздем.
Нужа капчыгымны сыртка салып,
Йөкне тауга илттем, тик түздем.

Гомеремнең язы — яшьлегемдә,
Сайлаганда тормыш гөлемне,
Мәхәббәткә чумган юләрлегем
Гөлгә күмде гомер көземне.

Омтылмадым алтын-көмешләргә,
Омтылмадым бөек тәхеткә.
Тар сукмактан олы юлга чыгып,
Алтын туйны төрдем бәхеткә.

Гомер көзем бик җимешле булды,
Бик шөкермен бүген көнемә.
Яшәртәсем, су сибәсем килә
Яшьлегемдә өзгән гөлемә.

Бер Ходаем! Сәҗдә кылып сорыйм,
Тигез канатымны каерма.
Бик яшисем килә, тик шулай да
Мине ялгызлыкта калдырма.

## *Швейцария истәлеге*

Бөтен дөнья яшел, һавасы саф,
Чисталыкка исең китәрлек.
Мөгамәлә чиксез сокландыра,
Муллык, байлык, хөрмәт җитәрлек.

Халык тыныч. Курку юк ул монда,
Корал тоткан кеше күренми.
Товар тышта. Алам диеп, беркем
Явыз ният белән үрелми.

Безгә сәер. Өстәвенә шунда
Бер исерек затны күрмисең.
Күргәннәргә күңел ышанмыйча,
Аңга килә алмыйча йөрисең.

Тузан юк бит, эзләп табалмыйсың,
Нигезе юк тузан бирергә.
Яшел үлән яки асфальт-бетон
Кешеләргә үтеп йөрергә.

Еллар үтәр. Әле алда, бәлки,
Бу оҗмахны күпләр күрерләр.
Кай җирләрдә, тездән сазда эшләп,
Ачлы-туклы яшәп үләрләр.

## *Бәхет тоям*

Үткәннәрен оныт диеп әйтмим,
Бүгенгесен искәр калаңның!
Чит җирләргә иялэшсә әгәр,
Кайтуларын телә балаңның.

Җил капкалы ямьле урамнарда
Рәссам кулы тигән матурлык.
Кибет киштәсендә, өстәлләрдә
Байлыкларга хәйран калырлык.

Урамыңнан үткән чакта, калам,
Горурлана йөрәк, күңелләр.
Көн дә арткан гүзәллекне күреп,
Бәхет тоеп үтә гомерләр.

Көч салмыйча, гүзәллекләр тумый,
Сәләт, теләк кирәк төзергә.
Шул кешеләр өчен саулык сорыйм,
Сабырлыклар сорыйм түзәргә.

## *Гүзәл калам минем*

Тауларыңа менәм, суларыңда йөзәм,
Төшләремдә йөрим болыныңда.
Ләззәт табам, яшәргә көч алам,
Горурланып җырлыйм җырымда.

Гүзәл калам минем, куеныңда синең
Анам җылылыгын тоямын.
Чит илләрдә йөрдем, күп калалар күрдем,
Тик сине өстенрәк куямын.

Ошбу гүзәллекнең, көчле бердәмлекнең
Акыл үзәгендә син, калам.
Сокланып туймаучы, сиңа дан җырлаучы,
Өзелеп яратучы мин — балаң.

* * *

Күренәсең дә китәсең,
Йөрәгемә ут салып.
Беләсең бит күңелемне,
Үлсен дисеңме янып.

Бир җылыңны тәннәремә,
Тынычлансын йөрәгем.
Тугрылыклы назларыңа
Ал җанымнан кирәген.

## *Көтәм әле*

Ялтырый да үтә, күз чагыла,

Җылылыгы тими тәнемә.
Күңел белән җылы эзләп киләм,
Юк, кермиләр минем хәлемә.

Бик тыңлыйсым килә
моң-җырларны,
Назлар көтә йөрәк, күңелем.
Сайраганын көтә уй-хыяллар,
Аңласа да мөмкин түгелен.

Зәңгәр күкнең йолдызлары сыман,
Чиген, санын тапмыйм теләкнең.
Дарулары аның бер йолдызда
Ялкынланган юләр йөрәкнең.

Йолдыз атылгандай бер бәрелеп,
Назларына күмәр таңнарны.
Сабырлыклар сорап көтәм әле
Кояш чыгар килер язларны.

## *Үтә гомерләр*

Сулар ага, урман үсә,
Үтә гомерләр.
Айга менәсе килсә дә,
Сүнә күңелләр.

Озак үттем, күп таптадым
Тормыш юлларын.
Үтте инде, ерак калды
Яшьлек елларым.

Тигез генә булмый инде
Үтәсе юллар.
Утлы, давыллы булмасын
Алдагы еллар.

Саулык, сабырлыклар сорыйм
Гомер көземә.
Сагыш, сарылар сипмәсен
Нурлы йөземә.

## *Гаделсез дөнья*

Балага конфет бирәләр
Анасын кочар өчен.
Түбәнлектән тартынмыйлар
Дәрәҗә алыр өчен.

Сандугачлардай сайрыйлар
Бик изге вәгазь белән.
Соңыннан мунча ягалар
Вәгазьле кәгазь белән.

Ягымлы сүзләр вакытлы—
Ул да коры тел генә.
Бик кызганыч: сайлаулар бит
Дүрт-биш елга бер генә.

Сайлау алды — изгелектә,
Сүгенми хәтта хуҗа.
Йомыш төшсә, тәмле телләп,
Сайлау үткәнче суза.

Икейөзлелек, гайбәт, гөнаһ…
Кайда икән изгелек?
Гөнаһ булса, түрәләрне
Яшен сугар иң элек.

Закон турында сөйләргә,
Күп белергә ярамый.
Закон кулланып яшәүне
Хуҗа кирәк санамый.

## *Яңа елга*

Саф һавасын сулап, ак кар ерам,
Яңа елдан көтеп уңышлар.
Мин ышанам, биеклекләр яулар
Киләсе елда да тырышлар.

Үтәч елы безне хурламады,
Мул уңышлар белән зурлады.
Кешеләрнең дусты эт елына
Бүген язам өмет җырлары.

Минем иман камил, якты күрәм
Килер язны, җәен, көзен дә.
Кабынырлар сүнмәс ут, йолдызлар
Яңа елның зәңгәр күгендә.

Һәр Яңа ел уңай тәэсир ясый,
Бәйрәм хисе биреп күңелгә.
Эт елы да бәхет төяп килсен,
Сакланырдай итеп гомергә.

Табигый хәл, әгәр булган булса,
Иске елда калсын моң-зарлар.
Ел буена безгә нур өстәсен
Яңа елда яуган ак карлар.

## *Башың имә*

Башны иям, сәлам бирәм
Күңелдән хөрмәт белән.
Ишеге тәбәнәкләргә
Имәсәм, башны бәрәм.

Шулай кайчак гел мәҗбүри
Башны түбән иясең.
Имәсәң, башыңның ташка
Бәреләсен беләсең.

«Иелгәнне кылыч кисми».
Бу — явызлар хөкеме.
Башкисәрдәй явызларга

Ризалашу түгелме?

Башың имә, мескенләнмә,
Горур күтәр башыңны.
Йоклап йөреп, өстәлеңнән
Алмасыннар ашыңны.

Җил-давыллар куркытмасын,
Өйрән каршы торырга.
Тормышыңны, көнкүрешне
Теләгәнчә корырга.

## *Зарланмыйк*

Эссе җәйдә боз яугандай,
Салкын кышта кар ява.
Табигать бит кешелеккә
Үзе чир, үзе дәва.

Салкын кыш. Һавасы саф.
Өшетә һәм туңдыра.
Эссе җәйләр, яз-көзләре —
Уңыш — тамак туйдыра.

Һәр уңайның киресе бар,
Зарланма кире килсә.
Күп сикермә, урыныңда кал,
Дәрәҗә киләм дисә.

Күккә карап төкермиләр,
Чишмәгә чүп түкмиләр.
Сабырсызны хуп күрмиләр,
Түзгәннәрне сүкмиләр.

Өйрән авырлык кичәргә,
Бик үрелмә биеккә.
Дәрәҗә дип күккә очма,
Җирдә яшә ничек тә.

Йә яңгыр дип, йә салкын дип
Зарлансак адым саен,
Тиз сүнәр яшәү дәртебез,
Тапмыйча тормыш җаен.

## *Яңа елга*

Ак кар ерып атлап киләбез без,
Саф һаваны сулап дәвага.
Зарланмыйбыз үткән елны сүгеп,
Зур бәхетләр бирсен яңага.

Яңа еллар борчылусыз булсын,
Яшел торсын бәйрәм безгә.
Тыныч күңел, бәхет бирсен,
Иркен булсын тормыш кирәгә.

Һәр мизгелнең гүзәллеген тоеп
Кышын, җәен, язын, көзләрдә,

Йөрсәк иде хезмәт җимешенә
Елмаюлар саклап йөзләрдә.

Туңдырмасын кышның бураннары,
Куырмасын кояш нурлары.
Еллар буе дәвам итсен иде
Шатлык чәчкән бәйрәм җырлары.

## ***Шөкер***

Күңелемдә кояшлы яз минем,
Бетерердәй салкын карларны.
Алгы юлларымда яктылык бар —
Оныттыра үткән зарларны.

Тигез, кара җирдә өйрәнмәсәң,
Бозлы юлда йөрү хәвефле.
Укуларны дәвам итеп булмый,
Алдан өйрәнмичә хәрефне.

Катлаулы бит гомер. Көне, төне бар.
Таң атмыйча, кояш калыкмый.
Гармун ватмый гына, гармунчы да
Гармун уйнау белән мавыкмый.

Бар кеше дә миллионер түгел,
Балда, майда үтми тормышы.
Яктылыкка чыга, хөрмәт яулый
Хезмәт сөйгән, уңган, тырышы.

Төнлә икән, көт сабырлык белән
Таң атканын, кояш чыкканын.
Ач күзеңне, тор да алдан йөгер,
Көтеп ятма дөнья купканын.

Яланаяк тирән сазны ердым,
Сабан сөрдем арык ат белән.
Күп сөйләштем сагышларга чумган,
Күз яшемә манган хат белән.

Шөкер менә, машинада чабам,
Балаларым үсте тезелеп.
Эзләп тапкан бәхетемне тоям
Алга яктылыкка үрелеп.

Сүнмә, өмет, шиңмә, гомер гөлем,
Сүрелмәсен яшәү теләгем.
Үреләмен якты гүзәллеккә,
Тәндә типкән чакта йөрәгем.

## ***Ардырма***

Үткән көннең тәмен эзләп йөрим,
Еракларда тәм иясен күзлим.
Өзгәләнеп тарта күңел — түзмим,
Тәмне кабатлауны телим.

Аңларсыңмы минем теләгемне,
Шашып типкән чакта йөрәгемне.
Көтәм, бәгърем, яннарыма килгәнеңне,
Тәмен саклыйм сиңа дигәнеңне.

Бәхет бит ул — эзләгәнне табу,
Тапканыңнан ләззәт алу.
Теләгәннән коры калу — яну,
Күңелеңә кара сөрем ябу.

Бәхет бирче, бәгърем, юк, яндырма,
Өметемне өзмә, калдырма.
Тап мөмкинлек, юкка табынма,
Сабырлыгым җитми, ардырма.

## *Мин бәхетле*

Юлларымның озынлыгын белмим,
Кая, тагын күпме барырмын.
Үтәлмәстәй тауга юл ярырмын,
Бәлки, юлда арып калырмын.

Барын уйлап, җиргә каты басам,
Тирән калсын диеп эзләрем.
Гомер буе йөргән юлларымда
Кешелеккә бәхет эзләдем.

Таң чыкларын ерып чыландым да
Кояш нурларында коендым.
Үтәлмәстәй тирән упкынында
Тешләремне кысып тыелдым.

Гомер үтте. Җырым ерак китте,
Ишетерләр безнең моңнарны.
Безнең заман серен ачыкларлар
Тыңлаучылар безнең җырларны.

Йөрәк эштә, күңелдә җыр иде,
Үрелгәндә ашлы табынга.
Күзләрдә яшь, нәфрәт уты янды,
Туган яктан киткән чагында.

Сагышларның күле тирән, кайнар,
Зур тырышлык кирәк йөзәргә.
Озын язлы көзне күрү өчен,
Сабырлыклар кирәк түзәргә.

Шөкер, Аллам! Күңелемдә җыр бар,
Гөлләр бирдең бүген көнемдә.
Җырларымда гомер дәвам итсә,
Мин бәхетле гомер көземдә.

## *Бәхет кирәк гомергә*

Синнән башка көннәр озын миңа,
Нидер югалткандай күңелем.

Каты борчылуда, сагыш-юксынуда
Үтмәсә иде алгы гомерем.

Син онытма, бәгърем, һич онытма
Бу дөньяда минем барлыкны.
Борчылулар, сагыш, юксынулар
Бетерә бит тәндә саулыкны.

Мөмкин булса, тотар идем сине
Күзләремә туры каратып.
Нинди бәхет тояр иде йөрәк,
Яши алсаң сөеп, яратып.

Соңлап кына килеп кердең дә син
Ут кабыздың минем күңелгә.
Соң булса да, олы бәхет тоям,
Бәхет кирәк бит ул гомергә.

## *Горурланам*

Күңел канатыма моңнар тулган,
Сиңа багышлыймын җырымны.
Гомерлеккә хөрмәт белән сакла
Йөрәгемдә булган җылымны.

Назлы сүзләремне, күзләремне
Файдаланмыйм башка урында.
Кайда йөресәм дә, гөлләр күзләсәм дә,
Уй-фикерләр синең турыда.

Зарлануым түгел, мактануым,
Горурланам сөя белгәнгә.
Мин бит кайтам ерак яшьлегемә,
Яннарымда сине күргәндә.

## *Кала бит, кала*

Алга кара, артка кара,
Гомерләр узып бара.
Йөргән юллар, сөйгән ярлар
Кала бит, бар да кала.

Тапкан маллар кала,
Йөрәкләрдә яра дөрләп яна.
Сулар өчен җитми һава,
Табып булмый һич тә дәва.

Тәкъдирләр дөрес язылса,
Гаделлек тигез ябылса,
Авыр булыр иде бездән калса,
Башкаларныкы барса.

## *Нәрсә ул?*

Абага чәчәк атамы?
Җиңешә алмыйм күрмәгәч.
Көя беләм, сөя белмим,
Каян белим күрмәгәч.

Мәхәббәтне күрсәң иде,

Бик мактыйлар күргәннәр.
Имеш, утында йөргәннәр,
Ничек пешми түзгәннәр?

Нәрсә икән ул мәхәббәт,
Сөйдергәч тә көйдергәч?
Кеше үләндәй шиңә, ди,
Мәхәббәте сүрелгәч.

Имеш, кешегә мәхәббәт
Очарга бирә канат.
Мәхәббәт могҗизалары
Һич тә бетми, ди, санап.

Дөньяда кешеләр юк, ди,
Мәхәббәтне белмәгән.
Эзләсә, аны күрергә,
Димәк, гомер сүнмәгән.

## *Нинди көч бу?*

Йомшак басып
Килеп күренә дә
Кинәт йөрәгемә үрелә.
Канат чыга,
Күңел оча,
Ул киткәчтен, бар да сүрелә.

Моңга төргән
Нинди көч бу —
Утка кертә, суга сикертә.
Дару, агу
Бутап бирә,
Тәнне ашый яки симертә.

Мәхәббәт бу
Гөнаһсыз,
Алла биргән бүләк кешегә.
Бәла таба,
Ачу кала
Кадерен белмәс хайван ишегә.

Янсаң иде,
Көйсәң иде,
Очынып йөрсәң иде.
Сөйсәң иде,
Сөелүнең
Кадерен белсәң иде.

* * *

Ничәмә ел безнең урамнарда
Ишетелми тальян моңнары.
Онытылды өчпочмаклы хатлар,
Йөрәк өзгеч солдат җырлары.

Искә төшкән саен, йөрәк әрни,
Яңаралар иске яралар.

Колакларда җырлар тынсалар да,
Күңелләрдә моңнар калалар.

Солдат җырын, тальян моңын тыңлап
Үскән буын үтте үз юлын.
Тарих битләреннән күп тыңларлар
Батыр солдатларның дан җырын.

Соңгы шаһитларның мин берсе бит,
Сагыш аша тыңлыйм моңнарны.
Йөрәгемдә шыңшыйм, яшькә күмәм
Солдат җырлап киткән җырларны.

* * *

Белеп булмый кайчан тәннәреңә
Соңгы кабат тәнем тиясен.
Күңелемә килә үлгәндә дә
Сөям сине, сөям диясем.

Гайрәт чигәр сәбәп булмаса иде,
Көнем үтсә иде сагынып.
Гомер күземдә дә йөрсәм иде
Кайнар мәхәббәткә табынып.

Сөю, мәхәббәт ул гомер өсти,
Канат куя күккә менәргә.
Йөрәгеңә дәртен, көчен бирә,
Авырлыклар килсә түзәргә.

Яшә, сөю, ничек булсаң шулай.
Тәме көчле яну-көюнең.
Мәхәббәт ул — Алла биргән бүләк,
Гөнаһысы булмый сөюнең.

## *Җаннар таштан түгел*

Беркемнең дә җаны таштан түгел,
Мәхәббәттә эри йөрәкләр.
Сөю-сөелү дә, назга күмелү дә —
Һәркем күңелендәге теләкләр.

Беркемнең дә җаны таштан түгел,
Илдән китсә, борчый сагышлар.
Һичкемгә дә Алла язмаса иде
Сагышларга чумар ялгышлар.

Беркемнең дә җаны таштан түгел,
Кан-яшь түгә, сынса канатлар.
Кешелеккә насыйп кылмаса иде
Аерылышу, ялгыз газаплар.

Беркемнең дә җаны таштан түгел,
Иркә, назга мохтаҗ күңелләр.
Сөю-сөелүдә ләззәт белән
Үтсен иде безнең гомерләр.

## *Акыл биргән*

Гомерләрнең һәрбер көне тора
Җавап табылмаган сораудан.
Кыш суыктан, җәен эсселектән,
Язын, көзен иртә кыраудан.

Печән өсте. Көчле яңгыр ява.
Кышын юлда каршы җил, буран.
Суда — балык, җирдә кошлар бетә.
Яз, көз иртән күрмәстәй томан.

Табигатьнең уңай яклары күп,
Җир туйдыра безне икмәккә.
Җиләк-җимеш, байлык шаккатыра,
Шөкрана кылыйк нигъмәткә.

Җавап кирәк булган сорауларга
Акыл, көчтән таулар ишелә.
Барын җиңеп гомер итәр өчен,
Алла акыл биргән кешегә.

## *Сөенегез*

Сиксән — сиксән инде. Алла безгә
Аерым өстенлекне бирмәгән.
Табигатьтән безне читкә куеп,
Син үзгәрәк яшә димәгән.

Бирәсен дә биргән тиешенчә,
Вакыт үткәч, алган тузганын.
Булганына шөкрана кылам,
Юк, кызганмыйм үткән, узганын.

Тиенемне гел төенләп йөрдем,
Кайчак шактый мулдан булса да.
Калдырмадым юлда кешеләрне,
Атым артык арык булса да.

Машинада чабам, канәгатьмен,
Берүк ягулыгы бетмәсен.
Хак сорамыйм, бар да утырсыннар,
Белгән, күргән җәяү йөрмәсен.

Ошый, ошамыймы, аралашам,
Кешелегем шулай яралган.
Шуның өчен бит минем исем
Ерак-еракларга таралган.

Сөенегез әле сиксәндә дә,
Мин рульдә үзем йөргәнгә.
Горурлану кирәк үз итсәгез,
Машинамда кеше күргәндә.

Килер бер көн, машиналар сүнәр,
Минем кирәк калмас кемгә дә.
Бик сөенәм бүген, күрә алсам
Кап-караңгы, ямьсез көндә дә.

## *Гомер көзендәге яз*

Табигый хәл, килер авыр бер көн,
Синме, минме алдан китәрбез.

Язлар кабатланмас, гомердә — көз,
Ялгыз калгач инде нишләрбез?

Кешеләргә хас бер күренеш ул —
Уйлар борчый күңелне.
Юк шул, көчләр җитми (зур үкенеч)
Мәңгеләштерергә гомерне.

Чәчәкле яз сыман гүзәл яшьлек
Бик тә кыска булып тоела.
Дөньябызны күмгән мул яшеллек
Көзен сары булып коела.

Яшьлегемне уйлап сагынам да
Юләр чагым күреп үкенәм.
Әй бер Аллам, Сиңа табынам да,
Тигез картлык бир, дип үтенәм.

Һәрбер таңда сине күрү — шатлык,
Аваз салу — зур бер наз бит ул.
Пар канатлы булып килгән картлык —
Гомер көзендәге яз бит ул.

Әле озак гомер итсәк иде,
Йөресәк тә таеп, абынып.
Кайчан да бер китми булмас инде,
Китмә берүк мине калдырып.

## *Авылым мәктәбенә*

Туган якның чишмә, инешләре —
Безне үстергән авыл бишекләре.
Яшәр өчен якты нур күрсәткән
Күз алдында мәктәп ишекләре.

Туган илем, туган-үскән авыл,
Укып йөргән авыл мәктәбем —
Онытылмастай матур мизгелләре,
Тирән хатирәсе үткәннең.

Беренче кат чүпрәк букча киеп,
Укырга дип килгән елларым,
«А» хәрефен ятлау, сабый дуслар
Бизәп яши гомерем юлларын.

Әти-әни, әби-бабайлардай,
Укытучым да күңел түремдә.
Классташларымны искә алам
Хөрмәт белән гомер көземдә.

Озак еллар, озын юллар үттем,
Дөрләп янып чабам һаман да.
Яшәү өчен ялкын чаткыларын
Алдым букча кигән заманда.

Безне озаткан мәктәп класслары
Буш булмады гомер-гомергә.
Иң кадерле, изге урын булып,

Мәктәп яши безнең күңелдә.

Гомер көзем. Күз карашым сүнә.
Яшим хис, хыялга чумып, абынып.
Сабый эзләремне, мәктәп ишекләрен
Гомер буе яшим сагынып.

Гомеремдә кылган изгелекләр
Мәктәбемдә алган орлыктан.
Белем чишмәсенә күзем ачкан
Мәктәбем, юк, сине онытмам.

Укытучы апа, абыйларым,
Күпләрегез инде киттегез.
Сез, изгеләр, бик күп кешеләрне
Белемле, бәхетле иттегез.

Киләчәгең берүк өзелмәсен,
Сиңа бәйле авыл сулышы.
Рухи байлык, гомер өстәячәк
Синең хезмәтеңнең уңышы.

## *Рухланып яши бел*

Гомер уза җил-давыллар белән,
Язмыш, ялгышларга буталып.
Иренеңә сөртер су тапмыйсың,
Төтенсез янасың ут кабып.

Аяз көнне кайчак яшен уйный,
Яңгыр суы күмеп агыза.
Салкын кышның явыз бураннары
Дөньясына ачу кабыза.

Ә кайчакта рухланган күңел
Тау күчерә, барын кичерә.
Рухланыр сәләт, көч табалсаң,
Бик күп кирәк түгел кешегә.

Көч тап, көрәш авырлыклар белән,
Сәбәп эзлә, үрел гөлләргә.
Рухланып әгәр яши белсәң,
Җиңү килер алгы көннәргә.

Алтын-көмеш һич тә бәхет бирми,
Ләззәт табалмасаң барыннан.
Син бәхетсез — әгәр югалсалар
Шатлык бирүчеләр яныңнан.

## *Табигый хәл*

Өчпочмаклы хатлар бик күп яздым
Йөрәгемнән тамган кан белән.
Утта янган тәннең кызуында
Сыкранган, көйгән җан белән.

Тик күңелдә өмет саклый алсаң,

Яшәү ялкыннарын сүндерми,
Кайнар мәхәббәтең яши бирә,
Эссе, салкыннарны сиздерми.

Көн дә аяз, кояш булмый, була
Көчле яңгыр, кышын бураннар.
Гөрләп, шаулап торган бәйрәм үтә,
Җансыз, тынып кала урамнар.

Табигый хәл — кеше гомерендә
Кичерә шул инде барын да.
Ни булса да өзелмәскә тиеш
Өмет чаткылары каныңда.

Мактaлмадым түгел, күп мактaлдым,
Сазына да чумдым муеннан.
Горурлыклар белән үкенечләр
Тигезләшкән, чыкмый уемнан.

Күп кичердем яхшы, яманын да
Соңгы чиге, шөкер, — түгәрәк.
Күзләремне саклый алса иде
Күккә чыгып очар «күбәләк».

## *Укытучыларга*

Бөек һәм дә бик җаваплы эш ул
Укытучы булу тормышта.
Барын аңлап, тәбрик итәм Сезне,
Бай булыгыз ныклы саулыкка.

Күңелемдә минем чәчәкләр бар,
Күңел чәчәкләре өзелми.
Изгелекләр чәчә, хөрмәт йөртә,
Ул чәчәкләр кулга бирелми.

Минем дә кулда чәчәгем юк,
Изгелекләр бик күп теләктә.
Аңларсыз, шәт, сүнмәс җылылыкны,
Булган хөрмәтемне йөрәктә.

* * *

Бик кадерле туган-үскән илләр,
Бар бит илдә изге җирләр.
Изге урын, изге җирле илләр
Рәхмәт яуган җирләр, диләр.

Изге җирдә кылган изгелеккә
Хаҗ савабын бирер Аллам.
Изгелекләр булса теләгеңдә,
Изге җирне белик алдан.

Изге җир бар. Ул — изге Болгар.
Изгелеккә син шунда бар.
Анда изгелекләр эзе калган,
Изгеләрнең каны тамган.

## *Улым Артур*

Син, онытым, белеп яшә,
Бик яратам үзеңне.
Кайбер чакта орышам шул,
Тыңламагач сүземне.

Олы ир-егеттәй итеп
Күрәсем килә, балам.
Үсеп китсәң, әбиеңне
Борчымас идең ялан.

Кем булырсың,
ансын белмим,
Сәләтле итеп күрәм.
Иншалла, бик мактаулы
Кеше булырсың тиздән.

Акыллы, тырыш кеше бул,
Хезмәтне ярат, улым.
Белемле, ягымлы булсаң,
Түрдән бирерләр урын.

## *Ташламагыз хәер-догадан*

Кан агышын тыңлап кайтып киләм
Атам нигезенә догага.
Әти-әни, туган, балалардан
Артык ни бар икән дөньяда?!

Яратамын туган-үскән җирне,
Каным тарта җанны яралап.
Шуңа кайтам, очар хәлгә килеп,
Тормыш урманнарын аралап.

Мәшәкатьле дөнья һәм катлаулы,
Нужа кыйный адәм баласын.
Тән һәм җаннарына җылы тапмый
Онытканнар ата-анасын.

Бәйләнешле бар да. Уңай, киресе бар.
Әгәр әдәп җуйса кешеләр,
Хәер-дога өмет итәр өчен
Фикер тапмый аның ишеләр.

Әти-әни, бабай-әбиләрем,
Ташламагыз хәер-догадан.
Горурланып, тыныч китсәм иде,
Күчкән чакта якты дөньядан.

## *Бәйрәм безгә*

Бәйрәм безгә. Истәлекле көн бит
Изге 12 нче сентябрь.
Кавыштык та яшьли, юләр чакта,
Гомерлеккә калдык бергә без.

Гомер юлы гади генә түгел,
Төрле чагы аның булгандыр.

Кайчагында сөю сүзләрен дә
Әйтә алмый калу шуннандыр.

Уйлап баксаң гомер юлларыңны,
Ни генә юк анда күрелгән?!
Теш-тырнагың белән дөнья куып,
Мактанган чак, кайчак үкенгән.

Тик шуны бел: сөйдем сине, бәгърем,
Бәяләми кайчак үзем дә.
Бәхет, яшәү бирдем микән сиңа,
Уйлап кара, бәгърем, үзең дә.

Кешелектә тигез, шома юллар
Беркемгә дә һәрчак бирелми.
Йөрәктәге якты сөю хисе
Авырлык килгәндә дә сүрелми.

Изге күңелеңә ярашмаган
Явыз сүзләр яра ясаса,
Рәнҗемә, кичер мине, иркәм,
Табаныңны үбәм яраса.

Мин бәхетле синең белән, иркәм,
Синең исем белән мактанам.
Нахак сүзләрдән
мәхәббәтебез җимешләре —
Тугыз балам белән акланам.

## *Наиләмә*

Картаябыз, бәгърем, картаябыз,
Тик барыбер өзелеп сөям мин.
Гомер буе егет булалмадым,
Шуны уйлап үзем сүгәм мин.

Табигать ул үзенекен эшли,
Теләк кенә җитми кирәккә.
Юкса гомер буе синең тормышыңа
Ямьнәр бирү булды йөрәктә.

Син — кадерлем минем, иң көчлесе,
Яшәү бирдең миңа ямь белән.
Мин бәхетле гомер көземдә дә
Синнән алган сихри тәм белән.

Мең-мең рәхмәт сиңа, фәрештәм,
Миңа яшәү, гомер биргәнгә.
Син янымда торсаң иде, бәгърем,
Үбә алсам иде үлгәндә.

## *Шатлык гомер өсти кешегә*

Һәр таң безгә шатлык бирсен иде,
Шатлык гомер өсти кешегә.
Гомернең бит һәр минуты кыйммәт

Гомер иткән безнең ишегә.

Шөкер, бәгърем, 59 ел бит
Бергә яшәп гомер үтәбез.
Шиңмәс өчен рухи куәт биреп,
80 гә дә инде җитәбез.

Сиңа бәхет, шатлык бирү уе
Минем теләгемнең түрендә.
Син бәхетле хисләр кичерә алсаң,
Бәхетлегә саныйм үзем дә.

Авыр көннәр, авыр кичерешләр
Күп булдылар алар гомердә.
Яшьле булсалар да, кичергәнгә
Канәгатьләнү сизәм күңелдә.

Зарланмыйбыз. Без язмыштан башка
Көч тапмабыз ерак китәргә.
И бер Аллам, насыйп кылсаң иде
Гомер көзен бергә үтәргә.

## ***Изге Болгарым***

Йөрәгемә җылы бирә аңлау
Яшәү урыным изге булганын.
Синдә бәхет, яшәү тәме таптым,
Изге урыным минем Болгарым.

Рабига күле сафландыра сыман
Саф һаваның пычрак, тузанын.
Даның синең еракларга киткән,
Изге җирем минем Болгарым.

Изге чишмәләрнең суын эчәм,
Йөзләремне шунда юамын.
Синдә тудым, синдә үстем, яшим,
Бәхет биргән изге Болгарым.

Табигатьтә булган гүзәллегең
Сиздермидер гомер узганын.
Фани дөньям синдә. Каберем дә
Синдә булсын, изге Болгарым.

## ***Авылга***

Мин авылда тудым, шунда үстем,
Сабан сөрдем малай чагымда.
Хәзер дә авыл юлын сайлыйм,
Туктап калсам тормыш чатында.

Икмәк исен тоям кырларымның,
Ипи, ит, сөт тәме телемдә.
Игенчегә дан җырлыйсым килә
Тамак туйган һәрбер көнемдә.

Авыллар бит — яшәү чишмәләре,
Тау-таш ватып бирә суларны.

Җир тырмалап икмәк үстерсәләр,
Кемнәр хөрмәтләмәс шуларны?!

Дөрес, кырлар бар да тигез түгел,
Табигать тә һәрчак сыйпамый.
Һәр урынга акыл, хезмәт кирәк,
Ялкаулансаң, уңыш сыйламый.

Табигый хәл: юллар бик бормалы,
Караңгылык баса көн үткәч.
Таң ата да, җанлана бар дөнья,
Балкып кояш җиргә нур биргәч.

Көн үтә дип һич тә борчылмыйк без,
Төн артында күрик нурларны.
Һич онытмыйк, ятлыйк җырлау өчен
Яңа музыкага җырларны.

Авыл урамында утлар сүнгән,
Кабынырлар алар, кабыныр!
Кешелекнең акыл дәрәҗәсе
Авыл хезмәтенә табыныр.

## *Һаман да*

Яшьлегемне кочып, илләр гиздем
Кайнап торган узган заманда.
Суынса да инде уттай яшьлек,
Юк, туктамыйм әле һаман да.

Урын түрдән, хезмәт билдән иде
Зур мактаулы калам Казанда.
Оныттылар, сүнде, диләр бугай,
Ә мин янам юкса һаман да.

Зур көрәштә үтте минем гомер,
Күңелемдә яши ярам да.
Уйлыйлардыр, бәлки, бетте диеп,
Юк, мин исән әле һаман да.

Мөмкин кадәр каты басам җиргә,
Эзем калсын алгы заманга.
Теләк барда көчләп югалтмагыз,
Югалмадым, яшим һаман да.

## *Ике дөнья өчен*

Күңелемдә минем кошлар тавышы,
Болыннарның чәчәк исләре,
Теләп түккән хезмәт, җимешләр,
Мәңге сүнмәс сөю хисләре.

Күңелемдә җылы йомшак җилләр,
Икмәк уңышлары кырларга.
Рухланган яшәү омтылышы,
Иң ягымлы сүзләр җырларга.

Йөрәгемдә дуслык, хөрмәт кайный,
Җиргә өстәр идем матурлык.
Саклау өчен горур кешелекне,
Бирер идем кыю батырлык.

Теләкләрем белән мин бәхетле,
Изгелегем ике дөньяга.
Кешелегем, кылган гамәлләрем,
Киткәч, арттан килер догага.

## *Ярый онытылган*

Яшьлеккә хас юләрлекләр белән
Шайтанланган чаклар күп булган.
Ярамастай эзләр тапталган да
Вакыт белән ярый онытылган.

Яшьли шаярулар гадәт булып
Сеңгән булса әгәр каныңа,
Картайганда дөнья күрмәс идең
Оятыңнан ямьсез даныңа.

Тормыш тәрбиясе бик көчле шул,
Суга ата, утта көйрәтә.
Яхшы белән яман аермасын
Хезмәт белән кыйнап өйрәтә.

Акыл иләп сайлый яшәү юлын,
Ап-ак итеп, пакьләп юа күңелне.
Юлларыңа өеп хезмәт биреп
Бәхетле итә алгы гомерне.

## *Яныма кил*

Язлар дөньябызга гөлләр бирә,
Җирдә табигатькә җан өрә.
Яннарымда сине күрә алсам,
Күңелемә кыш та яз килә.

Язын да бит каты кырау кайчак
Корыта чәчәктәге гөлләрне.
Кырауларга ирек бирми яшим,
Уйлап бергә үткән көннәрне.

Күңелемә язны син бирәсең,
Тәннәремә көчне өрәсең.
Яныма кил, җылыңны бир, юкса
Аңла минем шәмем сүнәсен.

## *Зур рәхмәт аңа*

Күңел шиңә, мендәр тарта башлый,
Рухи зәгыйфьләнә күңелең.
Рухланыр сәбәп, кешең булса,
Канатланып үтә гомерең.

Мин бәхетле: очып, янып яшим,

Җылы, иркә назга күмелеп.
Иртә таңнан күзләремне ачам,
Кояш нурларына үрелеп.

Мең рәхмәт су сипкәне өчен,
Корытмаска теләп гөлемне.
Алла бәхет, саулык, гомер бирсен,
Зурлаганга гомер көземне.

## *Изге эзләр онытылмас*

Үләрмен дә онытырлар дип,
Ник борчыла икән бу күңел?
Юкса беркемгә дә мәңгелеккә
Чиксез бирелмәгән бит гомер.

Табигый хәл: бар да килә, китә,
Кар-бураннар күмә юлларын.
Кайберләрнең эзе күмелсә дә,
Күп буыннар җырлый җырларын.

Яшәгәндә, җырлап, янып яшим,
Төземәкче булып яңаны.
Кылган изге гамәлләрем белән
Җырларымда гомерем дәвамы!

Юк, борчылма, күңел, миңа гына
Җирдә читтә тәхет корылмас.
Изге эзләремне җирдә ясыйм,
Изгелекләр озак онытылмас.

* * *

Төшләремдә күргән татлы төштәй,
Килеп күзләремә күрендең.
Янып яннарыңа үрелдем,
Китеп бардың, сүндем, сүрелдем.

Яраланган коштай, җиргә яттым,
Фикер, сәләтемне югалттым.
Йөрәгемне көчләп елаттың,
Тәкъдиремә сылтап юаттым.

Ай, кояшны күктә көткән сыман,
Килерсең дип көтә күңелем.
Белсәм дә бит тиңдәш түгелен,
Гел юксынып үтә гомерем.

Караңгылык басар сыман тоям,
Иртәгесен кояш чыкмаса.
Гомер дәвам итәр, бәлки,
Акылымны күңел тыңласа.

## *Су бир, яшәт*

Төннәр буе күңел сине көтте.
Таң атты бит, зинһар, кил инде.
Синнән башка бозланганын белеп,

Күңелемә җылы бир инде.

Күңел иркен — чикләнүне белми,
Тик тормыш бит чикли кирәкне.
Томаннардай файдаланып үтә
Йөрәк түремдәге теләкне.

Йөрәгемдә җылы, күңелемдә канат,
Томан аша гына күрсәм дә.
Эчемдә ут. Сусап су табалмыйм,
Берни булмагандай йөрсәм дә.

Су бир, яшәт, җылы сулышың өр,
Бик яшисем килә янсам да.
Мин бәхетле сине янда күрсәм,
Куе томаннарда калсам да.

## *Гомер өстәче*

Яз хәбәре, киткән кошлар кайта,
Дөньябызны күмәр гөл, чәчәк.
Бик бәхетле булыр идем, әгәр
Синең белән булса киләчәк.

Буш урын юк, бар да тигез тулган,
Нәфес дигәне дә туйгандыр.
Бәхет ишекләре бикле бугай,
Җаным үрсәләнү шуннандыр.

Алтын, көмеш, байлык бәхет бирми,
Күңелеңдә наз, ямь булмаса.
Нинди мәгънә соң, юлларыңда
Үрелергә гөлең тормаса.

Юлларымда өмет гөлем бит син,
Нур бирүче минем күңелгә.
Иркә назың, күңел язың белән
Көн өстисең алгы гомергә.

## *Насыйп кылчы*

Борчылганда орышмакчы булам,
Телем бармый начар сүзләргә.
Югалтудан куркып назларыңны,
Сабырлыклар эзлим түзәргә.

Күлгә чумсаң, коры калып булмый,
Тырышырга кирәк чыгарга.
Ләззәт, назларыңны саклау өчен,
Туры килә күп чак чыдарга.

Күңел куркынычы гаделсезлек,
Телләр шомартмасын ялганны.
Наз көткәндә, тоз кермәсен иде
Йөрәгеңә ясап яраны.

Сакла, Аллам, аны, үземне дә,

Пычратма чиста күңелне.
Бәхет, назлар белән насыйп кылчы
Кичерергә алда гомерне.

## Дан җырлыйсым килә

Яз уята барлык табигатьне,
Яз яңарта безнең күңелне.
Бар кешелек язның гүзәллеген
Хатын-кыздан башлый түгелме?

Юк ялгышлык, изге, гүзәл затлар,
Сез лаеклы бөек тәхеткә.
Ходай кушып ирешсәгез иде
Күңел тулыр олы бәхеткә.

Тормышның сез — гүзәл чәчәкләре,
Чыганагы иркә назларның,
Күңелләрнең мәңге бетмәс көче,
Табигатьтә — килер язларның.

Сездән башка җирдә кешелек юк,
Аналарсыз тумый балалар.
Рухланыр көчләр булмаганда,
Канатланмый авыл, калалар.

Сезнең белән күңел ләззәтләнә,
Сездән башка җирдә ямь, тәм юк.
Сулар өчен һава, кирәк дым да сездә,
Дөнья җылытырдай сездә ут.

Минем дә бит дан җырлыйсым килә,
Ишеттереп авыл, калага.
Зур хөрмәт, мең рәхмәт безне тапкан,
Безне үстергән газиз Анага.

## Туган ягым

Нократ буйларында ял иткәндә,
Иркенәйгән чакта сулышым,
Горурланам, чиксез бәхет тоям,
Гүзәл калам син, Мамадышым.

Туган якның изге туфрагы,
Чишмә, инешләре йөрәктә.
Әтиләрдән калган гүзәллекне
Мәңгелеккә илтү теләктә.

Тукай яңгырыдай яңгырларың,
Җиләк-җимеш урман, болында.
Күп шәхесләр сиңа дан җырлаган
Күңелендә туган җырында.

Хезмәт сөйгән горур кешеләрең,
Табигатең тарта үзенә.
Чәчәкле яз, җимешкә бай җәең
Гүзәллекләр өсти көзеңә.

Ак халатлы кышың саф һавалы,

Шаяргандай явыз бураның.
Күңеләңне яулап әсир итә
Ап-ак карлы кышкы урамың.

Туган ягым, бөтен җаным белән
Дан җырлыймын белеп кадерең.
Гомеремә күп чәчәкләр бирдең,
Синдә булсын иде каберем.

ЭЧТӘЛЕК

Табигать чишмәсе ул... *Әхмәт Гадел* ............

Мамадышым — бәхет калам .................
«Күңелемдә изге теләкләрем...» ..............
Мәңге яшә ..........................
«Март аенын җиләс җилкәйләре...» ............
«Күп күрәбез орден, медаль таккан...» ...........
«Бирер идем сезгә таң нурларын...» ............
«Гомер көзе. Гөлләр өзәм...» ................
«Март җилләре шаяралар кырда...» ............
«Тибеше үзгәрде йөрәкнең...» ................
«Син бит миңа, иркәм, наз бирдең...» ............
«Яшәү җиңел түгел кемгә дә...» ..............
«Көзен киткән кошлар кайтыр вакыт...» ...........
«Март, апрель — кышның курыкканы...» ..........
Акылыңны тупла ......................
Үпкәләмә ..........................
Элек алай түгел иде .....................
Язлар уяталар ........................
«Яфракларын койган ак каеннар...» ............
«Безне кешеләр сөйлиләр...» ................
Сәер булыр микән ......................
Солдат тормышыннан мизгелләр .............
Артыгы юк ..........................
Акланмады көткән өметләр .................
«Яңа яуган мамык карны ерам...» ...............
«Илне саклап үлгән батырларга...» .............
Кара безнең заманга .....................
Оныт .............................
«Син кимсенмә, нигә куналар, дип...» ...........
«Кешеләр бик тәмләп чәй эчәләр...» ...........
«Егет җилле, тик күлмәгем кыска...» ...........
«Күңелемдә изге хис, хыяллар...» .............
Бәйрәм бүген ........................
«Без кичергән шаулы ул елларның...» ...........
«Сагындыра инде үткәннәр...» ................
«Синнән башка ямь табалмыйм һич тә...» ..........
«Бәйрәм бүген, бар да бәйрәм итә...» .............
«Гәзиткә белдерү бирәм...» .................
Сәләт кирәк .........................
«Җитәкче дә, батырлар да — бар да...» ...........
«Мин — комиссар, политхезмәтчемен...» ..........
Әниемә ............................
Юк, зарланмам .......................
«Ихлас күңел, кайнар йөрәгемнән...» ...........
Рәхмәт, авылдашлар! ....................
Кайт тизрәк .........................
Янып китә алмадым .....................
Мең рәхмәт .........................
Юлларыма маяк кирәк ...................
Юксыну ...........................

«Без үскәндә, кысыр җир калмады...» ............
«Борчыма юк-бар сүз белән...» ................
«Очарга дип канат кагынганда...» .............
«Үпкәләтмә, күпме мөмкин көтү...» .............
«Бик теләсәң, тау тишәсең...» .................
Бәхетсезлек .........................
Куркам ............................
Юләрме?.. ..........................
«92 гә җитәсең, дип...» ...................
Онытма ...........................
Насыйп ит ..........................
Өмет сүнмәсен ........................
Ишетмиләр минем тавышны ................
Кем теләмәс .........................
Кайт тизрәк .........................
«Сугыш елы сабые һәйкәлен...» ..............
«Көннәр буе тулгак көттем...» ................
«Теләк, хыял, нәфес сүнмәсә дә...» .............
«Кытыгым да, ачуым да килми...» .............
Килер соңгы таңым .....................
«Һәркемнең дә үз үлчәве була...» ..............
«Кичер мине, әгәр күңеленә...» ...............
«Белмим, нигә кочаклады берәү...» ............
«Мәхәббәт җырларын элек...» ................
«Беркөн төштә саташканмын, каһәр...» ...........
«Гәүдә олы, фикер зурдан...» ................
«Картка санаган буламы...» ................
Җирдән китмә ........................
Язмышым куша .......................
Адашканнар турында ....................
«Керәшендә минем туганнар бар...» .............
«Очрашсам, чиксез бәйрәм тоям...» ............
Солдат дусларга .......................
«Сагындыра чебен-черкиләр...» ..............
«Җаным тарткан якынымның...» ..............
«Көз килгәнен беләм көннәремә...» ............
«Керәшеннәрне яратам...» .................
«Тыңла, ярат кошлар моңын...» ..............
Ә безнеке эчми-тартмый, ләкин артмый... .........
Мескен ............................
Ачык хат ...........................
«Чыр-чу килгән бала-чага сыман...» ............
Үткәнне һәм киләчәкне уйлап ................
Гомер көзем .........................
Тирән эзләр .........................
«Килер бер көн...» .....................
«Булган изгелекләремә...» .................
«Яшь чагында яшел була...» ................
«Соңгы җырым, йөрәк җылым сезгә...» ...........
«Әче җилләр ялмап искәндә дә...» .............
«Очрашсам, тулы назга чумам...» .............
«Мин дә явыз...» .......................
«Нинди көчләр миңа канат бирә...» .............
«Гүзәллекнең чиген белми күңел...» ............
«Сабан тургайлары сайрый...» ................
«Җир астыннан йөргән еланнар бар...» ...........
«Их, Мамадыш, Мамадыш...» ................
Тик ул гына .........................
Мин дә үпкәләдем ......................
Онытмыйк ..........................
Һәр гомернең була көзләре .................

«Очар чакта оч син биекләргә...» ...............
Күбәләк булма .........................
«Мамадышлылар сезне сәламлиләр...» ...........
«Шаулап муллык үсү...» ...................
Фатих Сәүбәновичка .....................
Туган авылым .........................
Пычратма намус, исемне ...................
Чиген бутама .........................
Син бәхил бул .........................
Ялган муллаларга нәфрәт ...................
Туган илем ...........................
Алтын бирер идем .......................
Ашыктырма, зинһар ......................
«Яратам мин барлык кешеләрне...» .............
Фәрит .............................
Фәридә язмышы ........................
Язлар китмәсен ........................
Кайтам .............................
Үзәгендә күңелнең .....................
Омтылырга кирәк яшәргә ...................
Гомер өчен саклыйк йөрәкне .................
«Колак озын, күзләр уйный...» ................
Югалма ............................
Гаделлек кирәк ........................
«Яраттым мин тузан ерган...» ................
Уйла .............................
Җырла, татар .........................
Тәрбия турында ........................
«Наркоманнар, эчкечеләр...» .................
Эзләр турында .........................
Шулай, дуслар .........................
Без бурычлы ..........................
Нигә кирәк ...........................
Акыл белән яшик .......................
Китәм инде ..........................
Яшәү бирсен ..........................
«Син теләгән кешең җавап итеп...» ..............
«Күп бурычларны түләргә...» .................
«Җәй көнендә урманнарда йөрдек...» ............
«Сандугачны хөрмәтлимен...» ................
Дустыма ............................
Үгет .............................
Җырлап барам алгы көнемә .................
Син — җимеше күңелнең ..................
Күңелемдә диңгез дулкыннары ...............
«Яңа ел яңа бәхетләр...» ...................
Гадел түгел ..........................
«Гомер юлым бик түмгәкле булды...» ............
Швейцария истәлеге .....................
Бәхет тоям ..........................
Гүзәл калам минем ......................
«Күренәсең дә китәсең...» ...................
Көтәм әле ..........................
Үтә гомерләр .........................
Гаделсез дөнья ........................
Яңа елга ...........................
Башың имә ..........................
Зарланмыйк .........................
Яңа елга ...........................
Шөкер ............................
Ардырма ...........................

Мин бәхетле ..........................
Бәхет кирәк гомергә ......................
Горурланам ..........................
Кала бит, кала .........................
Нәрсә ул? ..........................
Нинди көч бу? .........................
«Ничәмә ел безнең урамнарда...» ..............
«Белеп булмый...» .......................
Җаннар таштан түгел .....................
Акыл биргән ..........................
Сөенегез ...........................
Гомер күзендәге яз .....................
Авылым мәктәбенә ......................
Рухланып яши бел .......................
Табигый хәл ..........................
Укытучыларга .........................
«Бик кадерле туган-үскән илләр...» ............
Улым Артур ..........................
Ташламагыз хәер-догадан .................
Бәйрәм безгә ..........................
Наиләмә ...........................
Шатлык гомер өсти кешегә .................
Изге Болгарым .........................
Авылга ............................
Һаман да ...........................
Ике дөнья өчен ........................
Ярый онытылган .......................
Яныма кил ...........................
Зур рәхмәт аңа .........................
Изге эзләр онытылмас ....................
«Төшләремдә күргән...» ...................
Су бир, яшәт ..........................
Гомер өстәче ..........................
Насыйп кылчы .........................
Дан җырлыйсым килә .....................
Туган ягым ..........................

Заказное издание

***Галиев*** *Вахит Валиевич*

ПЕСНИ МОИ — ПРОДОЛЖЕНЬЕ МОЕЙ ЖИЗНИ

*Стихи*

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Заказ басма

***Галиев*** *Вахит Вәлиевич*

ҖЫРЛАРЫМДА ГОМЕРЕМ ДӘВАМЫ

*Шигырьләр*

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Рәссамы *Л.П.Петрова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.08.2006. Форматы $70\times90\ 1/32$. Офсет кәгазе. «Times New Roman» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,61 + форз. 0,15. Шартлы буяу-оттиск 8,50. Нәшер-хисап табагы 6,27 + форз. 0,26. Тиражы 1000 д. Заказ З-723.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.